Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 24 (1440) 23 июнь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

2

«Нәүрүз» фестивале илебездәге милли театрлардан үрнәк һәм гыйбрәт алу өчен бик кирәкле җыен ул.

12

«Агыйдел» ансамбле солисты, моңлы тавышы белән бихисап тамашачы күңелен яулаган Рәзилә Галиева күңелендә нинди серләр йөртә?

24

«Әкият» курчак театры өлкәннәр өчен тагын бер тамаша – шактый четерекле темаларны колачлаган «Авиатор» спектаклен тәкъдим итте.

Сабан туе рухы әйди безне Гомер бакый бердәм яшәргә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия Хөкүмәте югары уку йортларының талантлы студентлары һәм аспирантлары өчен академик Камил Вәлиев исемендәге стипендия булдырды.

- Казанны Россиянең 2024 елгы китапханә башкаласы итеп сайладылар.

- Армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең 100 еллыгы уңаеннан Тәтеш районында истәлек медальләре тапшырылды.

- Татар китабы йортында язучы Шәриф Камал һәм аның улы Йосыф Байгилдиевнең хатларына багышланган интерактив күргәзмә ачылды.

- Быел Татарстанда татар теленнән бердәм дәүләт имтиханын 9, татар әдәбиятыннан 1 укучы (Ихтыяр Кыямов) тапшырды.

- Мәскәүдә Татарстанның Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге бинасында «Шәрыкъ базары Казанда» милли мәдәниятләр фестиваленең презентациясе узды.

- Казан шәһәре башкарма комитеты тәкъдим иткән «Туган телләр поезды» проекты Милли мөнәсәбәтләр өлкәсендәге Бөтенроссия иң яхшы тәҗрибәләр конкурсында җиңү яулады.

- Чаллыда төшерелгән беренче тулы метражлы нәфис фильм – «Күкәйле гөл» комедиясе ачык интернетка куелды.

- Татарстан кунаклары катнашында Бакуда Сабан туе узды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Гөлдания ХӘЙРУЛЛИНА, җырчы, Татарстанның атказанган артисты:

«Башкортстанда бер әбинең сөйләгәне истә калган: «Әй, җырчылары төрле-төрле, җырлары гына бертөрле», – дигән иде. Хәзер бөтен кеше шигырь, көй яза, җырлар күп, җырлап бетерә алмыйлар. Җырларның «ертыклары» да күп, әмма халык арасында нинди җыр популяр булып китәр икән дип тә белеп булмый. Кайвакыт «ай, шәп җыр» дип уйлыйсың, ә халыкның исе китми».

СЫНАМЫШЛАР

26 июньдә кыяр чәчәргә ярамый, уңмаячак ● 29 июньнән күке белән сандугачтан кала барлык кош сайраудан туктый ● Бал кортлары дәррәү умарталарына таба очса, яңгыр ява ● Кырмыскалар ояларына кереп качса, көчле җил һәм яшенле яңгыр көтелә ● Урман җилсез шауласа – яңгырга.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **2 сәгать 59 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 33 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 34 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **4 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **30 июньдә 17 сәгать 30 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

25 июнь – Россиянең атказанган архитекторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Россия архитектура һәм төзелеш фәннәре академиясе мөхбир-әгъзасы Сәйяр Ситдыйк улы Айдаровның тууына 95 ел (1928–2014);

– хормейстер, педагог, Татарстанның халык артисты Венера Хәсән кызы Гәрәеваның тууына 80 ел (1943–2020).

27 июнь – драма актеры, татар эстрадасына беренче булып фокусчы һөнәрен керткән Габделхәй Хафиз улы Мөхәммәтшинның (Хәй Мушинский) тууына 115 ел (1908-1994);

– шагыйрь Фәннур Шәйхенур улы Сафинның тууына 75 ел (1948–1992).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 28 июнь.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(26 июнь-3 июль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 5 нче көне

СӘХНӘ

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА

Таулардан биек нәрсә бар?

Катнаш никахларны булдырмау, гореф-гадәтләрне кире кайтару өчен ни эшләргә? Хәзерге заман тамашачысына кызыклы тема, проблемаларны каләм очына элеп яза белгән драматургларны, заманча сәхнә телендә иҗат итә белүче режиссерларны каян алырга? Төрки халыкларның XVI «Нәүрүз» театр фестивалендә тамашачы һәм белгечләр күрсәтелгән спектакльләр аша һәм фикер алышулар барышында шушы һ.б. сорауларга җавап эзләде.

Быел төрки «Нәүрүз» фестиваленең үзенә күрә юбилее. Моннан нәкъ 25 ел элек ул беренче тапкыр Казаныбызда үткәрелә башлады. Һәр «Нәүрүз»не берәр халыкның театр сәнгатенә багышлау гадәте урнашкан иде. Быел Дагыстан, Чечня, Кабарда-Балкар театрлары килеп, Төньяк Кавказ халыклары көн үзәгендә булды. Кунак буларак Драма сәнгате мәктәбе һәм «Et Cetera» Мәскәү театры чакырылган иде. Танылган актер Александр Калягинның, сәхнәдә уйнап кына калмыйча, Г.Камал театрының кече залында тамашачы белән очрашуы фестивальдә истәлекле мизгелләрнең берсе булды.

Кавказ халыкларының театр сәнгате ни дәрәҗәдә, дигән сорауга җавап сөендерә дә, шул ук вакытта күңелгә шом да сала. Дагыстанда – 12, Төньяк Осетиядә 7 профессиональ театр бар, дип горурланып сөйләсәләр дә, безнең сәхнәләрдә ни җитешмәсә, аларда да шул ук нәрсәләр җитенкерәми. Шуларның берсе заманча драматургия булса, икенчесе – талантлы режиссерлар. Көн кадагына сугып иҗат итүче драматурглары булса, мәсәлән, Нальчиктан Кабарда театры «Ревизор»ны, Владикавказдан Төньяк Осетия театры Шекспирның «Ричард III» трагедиясен алып килмәгән булыр иде. Репертуарларында милли спектакльләр дә хәттин ашкан, билгеле. Драматургия мәсьәләсен хәл итү өчен, алар да мәдәни мираска әйләнеп кайта. Әмма ерак Казанга, Мәскәү, Санкт-Петербург театр тәнкыйтьчеләренә күрсәтергә дип, үзләре иң яхшы дип санаган һәм өр-яңа тамашаларын алып килгәннәр. Сабыйларча фикер йөртеп, халыкара мәйданда дан аласылары килгән. Мәскәү тәнкыйтьчеләренә исә Гоголь, Шекспир, Островский белән ярап булмаслыгын, милли авторларның йөрәк түреннән чыккан әсәрләр белән генә игътибар һәм ихтирам яулап булачагын күптән аңлыйсы да бит... Чыннан да, мөхтәрәм критиклар Түбән Кама театры Мансур Гыйләҗевнең «Бичура»сы буенча милли гореф-гадәтләр юкка чыгу турында ачынып куйган «Аксак» яки Кариевләрнең ислам динебезне данлаган «Йосыф» спектакленә караганда Чеховны, Гогольне, Шекспирны сайлады. Әмма аларны караганнан соң, нәтиҗә ясап, милли труппаларга җиткергән фикерләре бер дә сөендерерлек түгел иде. Хәер, Астана шәһәреннән «Театр А.И.» алып килгән «Сад» тамашасы тәнкыйтьчеләр күңеленә хуш килде. Чеховның «Вишневый сад» әсәре буенча иҗат ителсә дә, вакыйгаларны 1990 елларга күчереп, Казахстандагы алма бакчалары турында бәян иткәннәр, янәсе. Бу театрны, чыннан да, телгә алмыйча мөмкин түгел. Гомумән, Казахстанда театр сәнгате бик алга киткән һәм тамашачы моны «Нәүрүз» фестивальләренең берсендә күрде. Әмма «Театр А.И.» – эстрада йолдызы Айгөл Иманбаева оештырган шәхси труппа. Җырчының әйтүенә караганда, ул эстрададан килгән бөтен керемне шушы театрның иҗатына багышлый бара. Бездә гаярь булуга карамастан, милли телләрендә уйналган тамашада ара-тирә бер кирәкмәгәнгә рус сүзләре кыстырылуы бер дә күңелгә ятмады. Сәхнәдә телне чуплибез, дип уйламый инде артистлар, рус телле яки руслашып беткән тамашачыга аңлаешлырак булсын өчен шулай эшлиләр. Бездә дә эстрада җырчылары эшләгән акчаларына театр оештырса, яңгырдан соң гөмбә сыман үрчесәләр дә ярый...

● Түбән Кама театрының «Аксак» спектакле (М.Гыйләҗев).

Милли труппаларны тагын бер борчыган нәрсә – тел. Алтай театрында, әнә, милли телдәге спектакльләр белән акча эшләп булмавын, ачтан үлмәс өчен, милли телгә тәрҗемә белән рус классикасын куярга мәҗбүр булуларын яшермиләр. Адыгеядан театр берләшмәсе килгән иде. Ул милли һәм рус труппаларыннан гыйбарәт. Ә бит әле кайчан гына милли һәм рус труппалары аерым театрлар булып эшләгән, иҗат иткән. Җирле халыкның телен юк итү әнә шулай оптимизациядән башланганын яхшы беләбез. Владикавказдан «Саби» яшь тамашачы театрының «Волшебная свирель Ацамаза» исемле нарт халкы дастаны буенча куелган спектакльне караганда да күңелне ризасызлык тырнады. Артистлары яшь, чибәр, талантлы, барычы нәни тамашачыларга ярыйсылары килгәне көн кебек ачык.

● Кабарда театрының «Ревизор» спектакле (Н.Гоголь).

Тел темасына М.Гафури театры артистлары белән режиссер Римма Харисова куйган «Без... Варислар» исемле вербатим искитмәле иде. Артистлар хәзерге заман яшьләренең тел, милли моң, гореф-гадәт турында уйлануларын бәян итеп бер дигән спектакль куйган. Монологлар борынгы башкорт һәм хәзерге заман җырлары белән үрелеп бара. Заманча яңгыраса да, хәзерге җырларның асылы милли булып калганын аңлап шаккатасың. Болай да була икән бит! Югыйсә, бериш яшь иҗатчылар милли традицияләрне тар-мар итеп бетерә дә, бу җәһәттән тәнкыйть әйтә башласаң, өлкән буын заманнан артта калган, надан, берни аңламый, безне дә артка сөйри, дип акыл саткан була. Бер генә нәрсә күңелне тырнады – башкорт телен саклау мөһимлеге турында бу вербатимны татар телен камил дәрәҗәдә белмәүче татар кызы куйган...

Быел «Нәүрүз» фестивале бөек язучы Чыңгыз Айтматовның әсәрләре буенча куелган үзбәк, кыргыз, кумык спектакльләре белән, милли дастаннар нигезендә иҗат ителгән балалар өчен тамашалар белән дә истәлекле булды. Әлмәт театрының классигыбыз Г.Исхакый буенча иҗат ителгән катнаш никахлар турында «Ул әле өйләнмәгән иде», Түбән Каманың «Аксак» исемле яңа «Бичура»сын аерым телгә алмыйча мөмкин түгел.

Безгә барыннан да бигрәк Грозныйдан Х.Нурадилов исемендәге Чечен дәүләт театры алып килгән «Таулардан биек» спектакле хуш килде. 92 ел эчендә байтак авырлыклар күргән, үлеп терелгән театр бу. «Таулардан биек» – безнең «Зәңгәр шәл» кебек репертуарларының йөзек кашы. Төрле буын артистларны берләштергән күп кешелек бу тамаша бүген дә халык күңелендә яшәгән риваятьләргә нигезләнгән.

(Дәвамы 4 нче биттә).

ЯТ МАКСАТЛЫ МӘГАРИФ

Күптән түгел Казанда узган Россия белән дустанә илләр мәгариф министрларының «Киләчәкне формалаштыру» дигән халыкара форумы, Татарстанда Сабан туйлары кызган чорга туры килгәнгәме, җәмәгатьчелек игътибарыннан ничектер читтәрәк калды кебек. Дөресен әйткәндә, аның максатлары да башкарак булды бугай... Хәер, бу хакта һәммәсен дә үз тәртибендә карап үтик. Ошбу халыкара форумда 31 илдән (асылда, Кыргызстан, Таҗикстан, Төркмәнстан һәм Зимбабве, Катар, Мьянма, Экваториаль Гвинея кебек илләрдән, аралырында Абхазия, Көньяк Осетия кебекләре дә бар) 101 вәкил (шул исәптән 18 мәгариф министры) катнашкан. Кадерле кунаклар булып, анда Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән дә белгечләр килгән. Кыскасы, чараны оештыручыларның (РФ мәгариф министрлыгы дип белик) аны мөмкин кадәр колачлы һәм җитди итеп күрсәтергә тырышканлыгы сизелә.

РФ мәгариф министры С.Кравцов әйтүенчә, чит илләр Россиянең «Россия укытучысы чит илдә» проекты, БДИ үткәрү тәҗрибәсе, шулай ук талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү проектлары белән кызыксына икән. Шуңа күрә аларга илнең мәгариф өлкәсендәге алдынгы проектларын күрсәткәннәр. Мәгариф инфраструктурасына гына да бюджеттан 120 миллиард сум акча бүленеп бирелүе, мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзү, аларны җиһазландыру һәм бу өлкәдәге ремонт эшләренең махсус программалары булуы хакында да сөйләгәннәр. Министр сүзләренә караганда, форумда катнашучылардан күпләр мондый хезмәттәшлек һәм багланышлар урнаштыруны киләчәктә дә дәвам итү кирәклеге, ә урыс телен өйрәнү буенча мәктәпләр төзү һәм урыс телендә эшли торган ачык мәгариф үзәкләре булдыруны алга таба да туктатмау, шулай ук бердәм дәүләт имтиханын оештыру һәм үткәрү зарурлыгы турында сөйләгәннәр. Алай гына да түгел, форум кысаларында мәгариф өлкәсендәге хезмәттәшлек буенча дистәләрчә килешү дә төзелгән. Кыскасы, министр форумның бик тә уңышлы узуы турында белдерә һәм аның нәтиҗәләреннән канәгать калган. Ә аның төп нәтиҗәсен инде ул: «Россия открытая страна, с нами хотят сотрудничать, проводить обмен учителями, повышение квалификации, вместе организовывать детский отдых», – дип билгеләгән. Күренә ки, төп нәтиҗә сәяси булып чыккан. Димәк, форумны оештыруның максаты да шундый булган.

Инде форумда күтәрелгән кайбер проблемаларга да кыскача тукталып үтик. Әйе, анда сүз күбрәк партнер илләрнең тарихы вә мәдәниятенә хөрмәт белән карау, шулай ук дустанә илләр белән ачык хезмәттәшлек итү турында барган. Форумга юллаган видеомөрәҗәгатендә РФ Президенты В.Путин да Россиянең барлык континентлардагы һәр халык, һәр ил һәм һәр уникаль цивилизациянең үзенә генә хас үзенчәлекләрен һәм буыннар варислыгын тәэмин итүгә, шулай ук рухи вә әхлакый кыйммәтләрен дә саклап калуга булган хокукларын яклавы турында белдергән. Әмма сорау туа: Россиядә яшәүче төп халыкларның бу мәсьәләләрдәге хокуклары белән эшләр бүген ничегрәк тора икән? Аларның милли мәгариф системалары җимерүдә (димәк, үзләрен мәҗбүри рәвештә милли вә рухи ассимиляциягә дучар итүдә дә) һәм туган телләрен өйрәнүне чит телләрне укытудан да түбән дәрәҗәгә төшерүдә төп рольне нәкъ менә Кремль үзе уйнады түгелме соң? Ә РФ мәгариф министры С.Кравцов үзенең төп докладында Россиянең белем бирү өлкәсендәге казанышлары турында сөйләгән, БДИне ул, дөньяда тиңе булмаган, иң югары технологияле имтихан дип атаган, бу тәҗрибәне дустанә илләрдә дә җәелдерергә әзер булуын әйткән. Тик мондый мәгариф илдәге төп халыкларның рухи вә милли-мәдәни ихтыяҗларына җавап бирми. Димәк, ул алар өчен ят максатлы булып чыга. Чөнки, асылда, аларга туган телдә белем алу мөмкинлеге бөтенләй дә калдырылмаган.

Ә Россия Президенты ярдәмчесе А.Фурсенко (элегрәк ул РФ мәгариф вә фән министры булып та торган иде) үз докладында Татарстанны, төрле мөнәсәбәтләр, белем вә карашларны оештырып, бердәм дәүләт һәм көчле икътисад булдыруның бүгенге үрнәге итеп тә китергән. Ихтимал, моның артында экс-министрның республикадагы чын хәлләрне белеп бетермәве яисә җирле түрәләрне үсендерү тактикасы гына ятадыр. Форум делегатларына үрнәк итеп, Казандагы полилингваль «Адымнар» лицеен күрсәтүне дә шул җөмләдән карарга кирәктер. Чөнки ул да тышкы ялтырауга гына корылган. Кызганыч, бүгенге хәлендә бу проект, татар халкын милли мәгарифсез калдыргганда, аны тынычландыру өчен кулланылган ялтыравыклы алдавыч кына булып күренә. Ата-аналар фикеренә һәм социаль челтәрләрдәге бәяләмәләргә караганда, педагоглык һәм белем бирү дәрәҗәсе анда әлегәчә түбән кала, тәрбия эшләре дә аксый. Әлбәттә, мондый хәл чор таләпләренә берничек тә җавап бирә алмый. Димәк, татар халкының рухи вә милли-мәдәни ихтыяҗларына җавап бирердәй, тулы канлы мәгариф системасын булдыру бүген милләтнең кичектергесез һәм төп бурычларыннан берсе булып кала.

Фоат УРАЗАЙ.

Матбугатка белгечләр кими

КФУның Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең Милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Гарифуллин татар журналистикасы (Яңа милли медиа) бүлегендә бакалаврларга көндезге уку өчен бюджет урыннары булмавын әйтте.

«Быел көндез укуга бюджет урыннар юк. Читтән торып уку бүлегенә генә бар. Анда татар журналистикасында 30 бюджет урыны бар. Көндезге укуга бюджет урыннарының булганын да татар бүлегенә бирә идек. Бер елны да шулай урыннар булмады, быел тагын юк», – диде ул.

Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбендә «Журналистика» юнәлешенә көндезге бүлеккә барысы 50 түләүле урын бирелгән. Анда укытуның рус телендә икәнлеге күрсәтелгән, ягъни татар журналистикасы юнәлешендә түләүле уку урыннары да юк.

Читтән торып уку бүлегендә татар юнәлеше буенча, 30 бюджет урыныннан тыш, 10 түләүле урын да билгеләнгән.

Быелтыр татар журналистика бүлегенә җиде бюджет урын бирелгән, төркемгә калган укучыларны контракт ысулы белән җыю планлаштырылган иде. Васил Гарифуллин бер еллык түләү 150 мең тирәсе торуын әйтте. Кафедра мөдире быел магистратурада бюджет урыннарының артуын әйтте. Татар журналистикасында көндезге магистратурага 10 урын, ә читтән торып укуга 5 урын бирелгән.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.

Энциклопедия чыкса да, эш тукталмый

Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты башкарылган эшләренә нәтиҗә рәвешендә «Татар-информ» агентлыгында каләм ияләре белән очрашу уздырды.

«Безнең төп эшебез – институтыбызның исеменнән күренә – татар энциклопедиясен әзерләү һәм бастырып чыгару. Без 6 томлы татар энциклопедиясен рус һәм татар телләрендә бастырып чыгардык. Димәк, безнең төп бурычыбыз башкарылып чыкты. Шуңа күрә без хәзер яңа юнәлешләр эзлибез. Үзебезнең максатыбызны без Татарстанны, андагы халыкларны популярлаштыруда күрәбез. Безнең өчен бу иң әһәмиятле юнәлеш», – диде анда институт директоры Искәндәр Гыйләҗев.

Зур энциклопедия чыкканчы, башта халык иҗатына багышланган кечкенә китаплар дөнья күрәчәк һәм соңыннан бөтен мәгълүмат гомумиләштереләчәк. Әйтик, быел Татарстан халыкларының үзешчән сәнгать коллективлары турында белешмә, исемлек басылган. Быел үзешчән фестивальләр турында да китап чыгу көтелә.

Матбугат очрашуында хәбәр ителгәнчә, «Татарстан Республикасының торак пунктлары» энциклопедиясенең 2-3 томнары акча булмау сәбәпле басылмаган.

«1нче томы рус телендә 2018 елда чыкты. Аның татарча варианты хәзер нәшриятта ята. 2-3 томнары тулысынча әзер. Акча бирсәләр, без аларны шундук нәшриятка тапшыра алабыз. Финанс кыенлыклар аркасында эш тукталып калды», – диде И. Гыйләҗев.

Энциклопедиянең 1 нче томына Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевский, Әтнә, Әгерҗе һ.б. районнарның 1200 дән артык торак пункты кергән. Калган районнар буенча мәгълүмат 2-3 нче томнарда урын алган.

Иллюстрацияле фәнни-популяр басмага төбәкләрнең тарихы, шәхесләре, табигате, мәдәнияте, демографиясе, сәнгате, авыл хуҗалыгы тармагы, археологик һәм тарихи һәйкәлләре турында белешмә тупланган.

Паркта – дуслык күпере

Казан халкын һәм шәһәр кунакларын Идел буе халыкларының туган телләре һәм мәдәнияте белән таныштыру максатында «Древо жизни» проекты оештырыла.

Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Гүзәл Сәгыйтова проектның быелгы беренче чарасы башкорт мәдәниятенә багышланачагын әйтте.

«Древо жизни» проекты быел «Черек күл»дән Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркына күчә. Бер кичтә башкорт һәм татар сәнгате кушылачак. Моны дуслык күпере дип әйтсәк тә була», – диде Гүзәл Сәгыйтова «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Чараны оештыручылар сүзләренчә, кунаклар башкорт халкының милли костюмнары, музыкаль инструментлары, гореф-гадәтләре белән таныша алачак. Остаханәләрдә декоратив әйберләр ясап, кубызда, курайда уйнап карау мөмкинлеге булачак. Теләгән кеше башкорт биюе элементларын өйрәнә алачак. Музыка сөючеләрне халыкара бәйгеләр лауреаты Юлай Касыймов курай моңы белән ләззәтләндерәчәк.

Башкорт мәдәнияте белән танышырга теләүчеләр 5 июльдә кичке сәгать алтыда Горький паркына килә ала.

«Древо жизни» проекты 2022 елда башланып китте. Былтыргы чаралар мари, мордва, удмурт, чуаш милләтләренә багышланды. Быел кунаклар татар, башкорт, рус халыклары мәдәнияте белән танышачак (5 июль, 18.00 – башкорт мәдәнияте; 19 июль, 18.00 – рус мәдәнияте; 2 август, 18.00 – татар мәдәнияте).

Проектны Казан мэриясе һәм Татарстан халыклары Ассамблеясе оештыра. Чаралар милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

Рифат КАЮМОВ.

1 нче биттә – Түбән Камада узган Сабан туе күренеше. Фото: Салават Камалетдинов. («Татар-информ»)

Укмасый каберенә таш куелды

Казанның Яңа татар бистәсе зиратында Габдулла Тукайның дусты, замандашы, шагыйрь, дин әһеле Миргазиз Укмасый каберенә таш куелды, чардуган урнаштырылды. Таш һәм чардуган куюя эшен башлап йөрүче – шагыйрьнең авылдашы, тележурналист, Казан кооператив институтының Дәрдемәнд исемендәге Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина.

«Бу эш ике елга сузылды. Кабере өстенә плитә дә җәйдердек, чөнки караучысы юк. Моңа кадәр институтыбыз студентлары белән аның каберен чистартып йөрдек. Киләчәктә дә каберен карап торачакбыз. Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фондының башкарма директоры Нурия Һашимова ташны һәм плитәне куйдыруда матди ярдәм күрсәтте», – диде Ф.Абдуллина.

Миргазиз Укмасый белән Ф. Абдуллинаның бабасы аралашкан булган. «Алар дус булганнар. Беренче тапкыр Миргазиз Укмасыйның ташландык каберен күргәч, шаккаттым, – диде ул. – Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре Казанның Яңа татар бистәсе зиратын өйрәнгән. Шуннан соң алар каберләрнең фотоларын интернетка урнаштырды. Миргазиз Укмасыйның ташландык, беркемгә кирәк булмаган каберен күреп, моңайдым. Аның хәтта чардуганы да юк иде. Кычытканнар үсеп беткән, ташына да пумала куелган... Кабер югалыр дип, үземнең өскә шулкадәр авыр йөк алдым. Шөкер, Аллаһ Тәгалә ярдәменнән ташламады».

Кабер ташына Миргазиз Укмасыйның шигырь юллары язылган: «Калебең көзге булсын. Кер кунмаган, рухың – чишмә суы сафлыгы».

«Укмасыйның беркеме дә юк. Ул 1930 елларда репрессияләнә, безнең авылдан 6-7 кешене кулга алалар. Казан дәүләт медицина университетына укырга кергән кызы вафат була, хатыны да җан бирә. Аның тагын бер кызы була. Ул Сахалин якларына киткән. Мин аны эзләтеп тә карадым, әмма таба алмадык. Шулай итеп, Укмасыйның бер туганы да калмый», – ди Флюра Абдуллина.

Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе аның Тукай чорында яшәгән бөтен танылган шәхесләр турында мәкаләләр язып калдырганын, шигырьләр иҗат иткәнен әйтте. «Тамагын туйдырыр өчен балта остасы булып эшләргә мәҗбүр була. Мәкаләләрен, язмаларын чыгартмыйлар. Ул картлар йортында бакыйлыкка күчә», – дип сөйләде Флюра Абдуллина.

Аның әйтүенчә, татар зыялыларның ташландык каберләре бик күп. «Студентларны алып барып, чистарту эшен башкару – тәрбияләү чарасы. Каберләрне карап, чистартып торырга кирәк. Үзебезнең эш-гамәлләр белән яшьләрне тәрбиялибез. Хөкүмәт карарга тиеш, дип әйтергә иялəнгәнбез, ләкин ул мөмкин эш түгел. Каберләрне торгызу мәсьәләсендә якташлар да ярдәм итәргә тиеш», – дигән фикерен җиткерде.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Миргазиз Укмасыйның әле өйрәнелеп бетмәгән шәхес булуын телгә алды. Чарада Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, әдәбият галиме Зөфәр Рәмиев, Балык Бистәсе районы башлыгы урынбасары Фирдания Әхмәтҗанова, язучылар һ.б. катнашты.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Мәдрәсәләргә ярдәм

Татарстан Диния нәзарәтенең «Зәкят» Хәйрия фонды Татарстанның мөселман уку йортларына финанс ярдәм күрсәтү өчен онлайн-хезмәт ясады.

Онлайн-сервис «Мәдрәсәгә игелек кыл» исеме белән Фондның сайтында урнаштырылды һәм республикадагы 8 мәдрәсә, РИИ һәм КИУ файдасына читтән торып сәдака һәм зәкят бирү мөмкинлеген тудырды.

Теләгән һәркем әлеге уку йортлары үсешенә матди яктан ярдәм итә ала. Моның өчен сервиста аларның берсен сайлап алып, акча җибәрергә була. Хәйрия акчалары мәдрәсәләрнең матди тәэмин ителешенә, мөгаллимнәр һәм шәкертләр файдасына, кирәкле әдәбият, биналарны төзекләндерү, ашатуны оештыруга юнәлтеләчәк.

Татарстанның мөселман уку йортлары дини белгечләрне бөтен Россиянең мөселман җәмәгатьчелеге файдасына әзерли: биредә татар, рус һәм гарәп телле имамнарны һәм мөгаллимнәрне, мөселман, иҗтимагый, дәүләт оешмалары, дөньяви һәм дини уку йортлары өчен кадрларны укыталар.

«Мәдрәсәгә игелек кыл» сервисы аша сәдакалар Әлмәт, Буа, Кукмара, Мамадыш, Урыссу, Чаллы мәдрәсәләре, Казанның Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәсе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Казан ислам университеты, Россия ислам институты хисабына җибәрелә.

Таулардан биек нәрсә бар?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Аларда Аллаһка, аналарга, Ватанга, хатын-кызга, кешегә мәхәббәт чагыла. Барыннан да бигрәк берсе истә калды. Борынгы заманнарда Ватанга тугрылыкны сынау өчен, илбасарлар яу белән ташланды дип сөрән салганнар һәм Ватанны якларга иң соңгы килеп җитүчене кыядан ташлап үтерә торган булганнар, имеш. Чираттагы шундый сынау вакытында соңарган бер бичараны хөкем итәр алдыннан, соңга калуының сәбәбен беләселәре килә. Бичара кичә өйләнгән икән, кәләше куенында йокы татлы булганга соңга калган булса да, аксакалларның карары катгый – үлем! Әмма кыяу егетен кыядан ташлыйбыз дигәндә генә, ерактa тагын бер соңга калучы күренә. Хәзер инде бу инсаннан сорау алалар. Ул исә Ватанны яклау дигәндә гел беренче килеп җитә торган булдыклы, җитез, үрнәк бер егет икән. Ләкин бу юлы җыенга үзе махсус соңарган. Чөнки җиде ел яратып йөргән сөйгәне кичә кияүгә чыккан. Дөрес, башта ул кияү егетенең йоклап калып үлемгә дучар булачагын чамалап бик шатланган. Әмма сөйгәненә бәхетсезлек киләчәген аңлап, кияүне коткарырга булган. Ничекме? Үзе җыенга соңга калып… Шушындый асыл ир-егетләребез булганда, безгә бернинди дошман куркыныч түгел, дип, икесен дә исән калдыралар... Тетрәнерлек түгелмени? Чеченнар әле дә риваятьләрне олылап яши. Спектакльнең исеменнән күренгәнчә, риваятьләр аларда «таулардан биек». Һәркем үзе генә беренчелеккә омтылмыйча, милләттәшләрен әнә шулай якларга-сакларга өйрәнсә, безгә дә тел бетү, катнаш никахлар, Чеховның чия бакчасында «адашкан» Мәскәү тәнкыйтьчеләре – берсе дә куркыныч булмаячак.

● Сырдәрья театрының «Анам кыры» спектакле (Ч.Айтматов).

● Төрек дәүләт театрының «Мәңгелек» китап кибете» спектакле (С.Кодрәт Аксал).

● Россия Умартачылык фәнни-тикшеренү институты мәгълүматлары буенча, илдә ун ел эчендә бал кортлары 40 процентка кимегән. АКШта кыргый умарталарның 90 проценты юкка чыккан. «Органик игенчелек берлеге» галимнәре фаразлавынча, алга таба да шулай дәвам итсә, 2035 елга бал кортлары бөтенләй үлеп бетәргә мөмкин. Бу очракта бүген игелә торган агрокультураларның өчтән берен үстерү тукталачак, чөнки үсемлекләрнең 75 процентын бал кортлары серкәләндерә. Альберт Эйнштейн: «Умарта кортлары юкка чыкса, кешелек дөньясы дүрт елдан артык яши алмаячак», – дип әйтеп калдырган.

● Дөньяда барлыгы 50 миллионнан артык корт күче исәпләнә, алар елына миллион тоннадан артыграк бал җитештерә. Бер умарта күче сезонга уртача 27-45 килограмм бал туплый. Бер кашык балны 200 корт көн буе җыя. Умарта күчендә 15 меңнән 80 меңгә кадәр бал корты булырга мөмкин. Эшче кортлар җәен 3 атнадан 6 атнага кадәр яши һәм шул вакыт эчендә бер кашык бал җыеп өлгерә.

«Мәскәү татар штабы» исеме белән эшчәнлек алып барган иҗтимагый оешма үз исемен «Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» атына үзгәрткән. Озак та узмыйча, ул төрле шәһәрләрдә, шул исәптән Казанда, үзенең бүлекчәләрен булдыра башлады. Без шушы хакта кызыксынып, «милли конгресс»ның җитәкчесе Рөстәм Ямалеевка мөрәҗәгать иттек.

Җәмгыятьнең бердәм булуы әһәмиятле

– Рөстәм әфәнде, сез җитәкләгән оешма озак елар дәвамында татар милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, бәйрәм-йолаларын һәм, иң беренче чиратта, татар телен саклап калу юнәлешендә эшчәнлек алып бара. Ә менә «Мәскәү татар штабы»ның исемен алыштыру нигә кирәк булды?

– Февраль аенда без «Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы»н оештыруны төгәлләдек. Без аны бик озак рәсмиләштердек. Уставларны да алыштырырга туры

килде. Ни өченме? Штабның вәкаләтләре таррак иде. Хәзер хокукларыбыз зуррак, киңрәк. Без Россиянең 44 субъектында, Урта Азия республикаларында, Луганск, Донецкида эшли, ассамблеялар, вәкиллекләр белән турыдан-туры элемтәгә чыга алабыз. Безнең устав бик универсаль. Юстиция министрлыгына оешманың документларын тапшырдык һәм, безгә үз иреклләре белән ярдәм итүчеләрне табып, Казанда, Чаллыда, Уфада, Түбән Камада, Ижауда һ.б. шәһәрләрдә бүлекчәләребезне ачтык. Гомумән алганда, Россиянең 20 шәһәрендә бүлекчәләребез эшли. Юстиция министрлыгында җаваплы кешеләребез бар, документлар, эш кәгазьләре барысы да рәсмиләштерелгән. Әмма чын эшчәнлегебез әле башланмады дияргә мөмкин. Казанда оештыру киңәшмәсе үтте, Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы әгъзаларын җыеп киңәшләштек. Алар безнең эшчәнлегебез турында белә. Утырышта олуг галимнәребез Хатыйп Миңнегулов, Индус Таһиров, Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы җитәкчесе Рәүф Хәсәнов чыгыш ясады, безнең эшчәнлегебезгә югары бәя бирделәр, Казанда бүлек ачуыбызны хупладылар.

– Казанда бүлекчәгез булдырылгач, төп офисыгызның кайда булачагы да тәгаенләнгәндер инде?

– Без әлегә Казанның Спортивная урамында эшчәнлек алып бара торган «Аксу» продюсерлык компаниясендә урнаштык. Хәзер оештыру эшләре бара. Без Казанда эшебезне Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә алып барырга телибез. Бөтендөнья татар конгрессының милләттәшләребезне берләштерүдә, гореф-гадәтләребезне, телебезне саклауда, тарихыбызны барлауда әйтеп бетергесез зур эшләр алып баруын һәркайсыбыз белә. Әмма алар колачлап бетерә алмаган юнәлешләр дә бар. Без бүген шундый ике мөһим юнәлешне күрәбез. Әйтик, институт-университетларда, көллиятләрдә татар яшьләренең иҗтимагый оешмалары булдырылмаган. Ул бик сирәкләрендә генә бар. Ә Казан һәм Уфа урта һәм югары уку йортларында татар яшьләре белән эшли торган оешмалар булдыру бик кирәк. Чөнки бүген яшьләребезнең күбесе туган телебездә аралашмавын танырга кирәк. Сөйләшкәннәре арасында да татарча язып аңлашырдайлары аз. Яшьләрнең 10 проценты кына татарча яза-укый белә. Без татарга үз телебездә мөрәҗәгать итәбез, әмма ул русча җавап бирә. Сәбәбе нәрсәдә? Бу – татар яшьләренең башка милләтләр белән кушыла баруы. Тәрбия эшләрен татар телендә алып бара торган тәрбиячеләр, репититорлар кирәк.

Безнең Мәскәү югары уку йортларында, яшьләрне оешмабызга җәлеп итеп, алар белән төрле кичә, очрашулар үткәрү тәҗрибәбез бар. Бу, беренче чиратта, яшьләрнең башка милләтләр белән кушылуга каршы көрәшүнең бер ысулы. Без оешмабызда татар студентлары мохите тудырып, милләтебезнең күренекле шәхесләре, галимнәре, әдипләре белән очрашулар, милли чаралар, төрле концертлар оештырабыз, походларга чыгабыз. КВНнар, квестлар үтә, яшьләрне шулай ук «Аулак өй» кичәләренә җыябыз. Студентлар белән эш җайга салынган. Һәр уку йортында татар оешмалары бар, студентлар белән төрлечә кичәләр үтә. Барысы да инициативадан тора.

Без Казанда да нәкъ менә шул эшне алып барырбыз дип планлаштырабыз. Без монда язучыларны, җәмәгать эшлеклеләрен, пенсиядәге укытучыларны, җәлеп итәргә телибез. Моннан тыш, без төрки халыклар белән эшлибез. Бу юнәлешне Татарстан белән Башкортстанда да алып барырга ниятлибез. Безнең телләребез, диннәребез бер.

Безнең активистларыбыз монда эшли башлады инде. Җитәкчелеккә килгәндә, без берничә кеше белән сөйләшүләр алып барабыз. «Татарстан» телевидениесендә берничә әңгәмә үткәрдек, матбугатта яздык, берничә киңәшмә уздырдык, Түбән Камада конгресска яшьләрне җыеп сөйләштек.

Тагын бер мөһим юнәлешебез бар: мәктәп укучылары арасыннан талантлы, актив ул-кызларыбызны барлап, булачак җәмәгать эшлекләләрен ачыкларга телибез. Мәктәптә укучылар арасында талантлы физиклар, математиклар, спортчылар һ.б. бар. Әмма безнең бурыч – алар арасыннан булачак Шәймиевләрне, Миңнехановларны, Шәйхразыевларны, җәмәгать эшләре белән шөгыльләнәчәк актив яшьләрне, иманлы, рухи бай, милли үзаңы үскән, милләтебезнең дәүләт тоткан, данлы тарихы булган халык икәнен аңлаган, татарлыгы белән горурланган укучыларны ачыклау. Без Казанның 15 нче гимназиясендә, «Солнце» мәктәбендә булдык. Актив укучыларны үз контролебезгә алып, алар белән аралашкачкабыз. Шушы эшчәнлекне алып бару ниятеннән, мәктәпләр, көллиятләргә йөрибез.

Без ике бурычны алга куябыз. Туган телебезне, борынгы милли гореф-гадәтләрне һәм йолаларыбызны саклау, икенчесе – яшь кадрларны сәяси эшчәнлек буенча карьера баскычыннан күтәрү. Татар егет-кызлары депутатлар булсын.

Без соңгы вакытта кичәләребезгә православие динендәге татарларны да чакырабыз. Төрки халыклар арасында да православие динендәгеләр бар. Аларны шулай ук чараларда катнаштырабыз. Россия – күп конфессияле ил, җәмгыятьнең бердәм булуы бик әһәмиятле.

Мәскәүдә Татарстан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт якташлар җәмгыятьләре бар. Алар барысы да безнең оешмага җәлеп ителгән, аерым-аерым чакырып, киңәшләшеп торабыз. Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә хезмәт итәчәгебезгә, аларның алып барган киңкырлы эшчәнлеген үзебезнең яңа юнәлешләребез, кадрларыбыз, ресурсларыбыз белән тулыландырачагыбызга өметләнәм. Безнең бурычларыбыз, программабыз, максатларыбыз бер.

– Сез Бөтендөнья татар конгрессы оештырган барлык форумнарда катнашасыз, алар турында да үз фикерләрегезне әйтсәгез иде.

– Күптән түгел генә «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында катнаштым. Бөтендөнья татар конгрессы уздырган бу эшлекле җыенга Россиянең барлык почмакларыннан хәзрәтләр килгән, аларга волонтерлар ярдәм итә. Утырышта кирәкле, көн кадагындагы мәсьәләләр уртага салып сөйләшенде. Чараның тонусын Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов та күтәрде. Без Казанның Агросәнәгать комплексы белән дә таныштык. Ул хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагыннан килгән кунакка күрсәтерлек хәләл продукция базарына әверелгән. Моңа бик шатландык. Агросәнәгать комплексы килгән кунаклар өчен әйбәт үрнәк булды. Алар моны, бәлки, үзләрендә дә булдырырга теләр. Россиядә хәләл бизнесы елдан-ел көчәя һәм киңәя. Бу – уңай күренеш. Моны хупламый мөмкин түгел.

Безнең мәчетләребез, мәдрәсәләребез, мөселман уку йортларыбыз хәтсез. Шәкертләрне дә шушы чараларга чакыру, өлкән яшьтәге имамнарыбыз белән аралаштыру әйбәт булыр иде. Яшьләрне, мәктәп укучыларын, шәкертләрне һәрвакыт Болгарга алып барып, ата-бабаларыбыз җирен күрсәтергә тиешбез. Татар телен, милләтне саклауда безнең динебез, уку йортларыбыз әһәмиятле эш башкарган. Хәзрәтләргә вәгазьләр бары тик татар телендә генә булырга тиешлеген тагын бер кат искәртү мәслихәт. Дин әһелләренә ышану, ихтирам бик көчле. Алар шулай ук татарча тормыш рәвешен, гореф-гадәтләр, йолаларыбызны пропагандаларга тиеш. Соңгы елларда татар телен белмәгән яшьләребез дә дингә килә, ураза тота башлады. Шуңа күрә хәзрәтләр аның төп эчтәлеген – таң вакытыннан алып кояш батканчыга кадәр ашамый-эчми генә тору түгеллеген, уй-гамәлләребез дә хәләл булырга тиешлеген аңлатырга тиеш. Яшьләребезне уразага алдан ук әзерләү сорала. «Беренче намаз» дигән чараны традициягә кертү бик зур әһәмияткә ия. Бу уңайдан тәҗрибәбез бар.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.



Танылган әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, нәшир, республиканың М.Җәлил һәм Г.Державин исемендәге премияләре лауреаты Мөдәррис Вәлиевкә, исән булса, 70 яшь тулган булыр иде..

Шагыйрь һәм наширне искә алу

Бер төркем каләм әһелләре, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, туганнары Казанның Киндерле зиратында әдипне искә алды, аның рухына дога кылды. Мәрасимдә чыгыш ясаучылар М.Вәлиевнең күп үрләрне егетләрчә яулаган киңкырлы шәхес булуы хакында горурлык белән сөйләде. Соңрак хатирәләр «Тантана» ресторанында дәвам итте. Искә алу кичәсен М.Вәлиевнең хатыны – Даимә ханым һәм кызы Айсылу оештырды.

М.Вәлиевнең беренче шигырьләренә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин хәер-фатиха биргән булган. Аның әйтүенчә, әдәби тәнкыйть өлкәсендә танылып, аксакаллар тарафыннан югары бәя алса да, М.Вәлиев татар әдәбиятында шагыйрь буларак аваз сала.

– Аның тәүге шигырьләре 16 яшендә үк минем кереш сүзем белән «Татарстан яшьләре» газетасында дөнья күрде. Мөдәррис Вәлиев – әле бүгенгә кадәр тиешле бәясен алмаган, бүген дә заманча яңгырыш торган элитар шагыйрь. Нечкә күңелле иде, киләчәкне фаразлап иҗат итте. Дуслары аны зур галим дип таныды, ул зур гамәлләр кылды. Китап хәрәкәтендә күренекле эш башкарды, тарихка керерлек китаплар иҗат итте.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла М.Вәлиевне беренче карашка аз сүзле, салкын күзле кешегә охшаган итеп исендә калдырган.

– Ләкин бер сөйли башласа, аны туктатуы кыен иде, бүлдерергә җөрьәт итми идек, чөнки шулкадәр матур сөйли, җөмләләре дөрес! Аның теле дә гаҗәеп әдәби. Редакцияләрдә эшләп, әдәбиятта абруй казанды. Тәнкыйть мәкаләсе язса, аның фикеренә колак салмыйча мөмкин түгел иде. Ул, чыннан да, әдәбият белгече, галим булды. Шагыйрь буларак, аның иҗаты әле өйрәнелмәгән, бәяләнмәгән. Нәшриятчы буларак, Харитонов, Кәримовлар, Рәмиевләр кебек, М.Вәлиевнең дә исеме китап басу тарихында тарихка кереп калыр, дип уйлыйм.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин М.Вәлиев белән 20 елдан артык аралашып яшәгән. Ул аны үзенчәлекле шәхес, дип искә ала:

– Өлгереп җитүен сизгәч, кандидатлык диссертациясен яклады, аерым юнәлешләр буенча яшьләргә белем бирү белән дә шөгыльләнде. Ул тагын бер тапкыр татар халкының китаплы халык икәнен дәлилләде. Без бүген дә аны юксынабыз. Ул безнең күңелдә, безнең арада.

1990 елларда, республикада барган зур үзгәрешләр, милли күтәрелеш елларында китап аша барлык юнәлешләргә дә тәэсир итә алды ул. Дистәләгән, йөзләгән кешене китаплы итте. Дәреслекләр, сүзлекләр... Янына кем генә килми, һәрберсе аның китапны югары дәрәҗәгә җиткерәчәгенә ышана иде. Ул китаплар Мөдәррис абый кулы аша узганга күрә генә сыйфатлы, дәрәҗәле булып басылды.

М.Вәлиевнең хатыны Даимә Вәлиева да ирен юксынып искә алды:

– Искә алу кичәсенә җыелган шәхесләргә карап, Мөдәррснең бу тормышта токтан урыны, эшләгән эшләре чынлап та ихтирамга лаек икәненә ышанасың. Мөдәррискә 70 ел тулды. Асылда 70 яшь тулды, дип әйтәсем килә, чөнки ул исән, һәрвакыт янәшәмдә кебек. «Үлгәннәрнең түгел, онытылганнарның гына гомере кыска», – дип язган иде ул.

Бу сүзләргә кызлары Айсылу Вәлиева да кушылды:

– Киндерле зиратында дәү әниебез – әтинең әнисе ята. Шулай ук туганыбыз – Шамил Маннапов һәм тагын берничә туган җирләнгән. Әти тормышта купшылык яратмады. Ташны без дин кануннарына туры китереп, сурәтсез ясарга тырыштык. Үлгәннәргә безнең дога кылуыбыз кирәк. Шуңа күрә сеңлем Гөлназ белән әтине догадан калдырмыйбыз, балаларыбызны да дәү әтиләрен искә алырлык, дога кылырлык итеп тәрбияләргә тырышабыз.

Туганнан туганы Рамил абый:

– Безнең авылда аны Салих абый дип беләләр. Безгә чәчен алдырырга килә иде ул. Нык оялчан иде! Ә үзенең өендә ул батыр, оештыручан кеше иде. Аралашып яшәдек, – диде ул.

М.Җәлил премиясе лауреаты Рәмис Аймәт М.Вәлиев белән иҗатта да, тормышта да якын дуслар булган:

– Аралашкан, хезмәттәшлек иткән дуслар күп. Ә сине аңлаган, сиңа һәрвакыт ярдәм итәргә омтылып, ашкынып торган, син аңа ышанган дуслар сирәк була. Әнә шундый ышанычлы дусларның берсе – Мөдәррис Вәлиев. «Мәгариф» нәшриятында ул ике китабымны чыгарды, шуңа күрә аңа гомер буе рәхмәтле булып яшим.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры Әнәс Әскәров әдипнең бик ачык күңелле, үзүзен тотышы, гыйлеме белән өлге, үрнәк булуын искә алды. КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов М.Вәлиевнең «Нәшрият эше һәм редактор хезмәте» дигән белгечлек буенча студентларга махсус курс укып, шәкертләр тәрбияләве хакындагы хатирәләре белән уртаклашты.

– 2000 еллар башында без аның белән булачак филологларга өстәмә белгечлек буларак «нәшрият эше һәм редакцияләү» дигән профиль керттек. Шактый еллар М.Вәлиев безнең студентлар белән бик уңышлы эшчәнлек алып барды. Бүген ул әзерләгән белгечләрнең дистәдән артыгы әлеге өлкәдә хезмәт куя. Быелдан төп белгечлек буларак, нәшрият юнәлеше өчен белгечләр әзерли башлыйбыз. М.Вәлиев әзерләгән методик кулланмаларга, аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итәбез.

Галим, техник фәннәр докторы, КФУ профессоры Җәүдәт Сөләйманов М.Вәлиевне саnaклар өлкәсендәге сүзлек авторларының берсе булуын искәртте. Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров М.Вәлиев белән Аккош күле буендагы дачасында күрше булган:

– Дөньяны профессионаллар тота. М.Вәлиев шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе, галим, педагог, нашир буларак, үзен чын профессионал итеп танытты. Безнең татар язучылары элек-электән оештыручылар булган. Мөдәррис тә юктан (нульдән) «Мәгариф-Вакыт» нәшриятын барлыкка китерде, аны үзенең дәвамчыларына калдырды, – диде ул.

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис М.Вәлиев белән «Казан утлары»нда эшләгән.

– Кешенең характерлый белә торган нәрсә – аның сорау бирү осталыгы. Дөрес һәм кирәкле җавап бирә белер өчен, акыллы булырга тиешсең. Мөдәррис һәрвакыт төгәл һәм катгый итеп сорау бирә белә торган кеше иде. Әдәбият, тормыш, җәмгыять белән кызыксынды. Мөдәррис татар китабының культурасын, эстетикасын үстерде. Үзенең таләпләрен куя белде. Нәшриятында әнә шул эстетиканы булдырды. «Мәгариф» нәшриятындагы китапларга күз салсагыз, шуны күреп була.

«Сәхнә» журналы баш мөхәррире Зиннур Хөснияр М.Вәлиевнең туган ягында – Әлки районында Нәби Дәүли исемендәге мәктәптә искә алу кичәсендә булган. Аның әйтүенчә, Мөдәррис Вәлиевне якташлары ярата, хөрмәт итә, ә иң мөһиме – иҗатын белә. Мөдәррис Вәлиевнең якташлары – китап җанлы, ди ул.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тәрҗемәчесе Гөлназ Исмәгыйлева, М.Вәлиев белән хатыны Даимә апа үзләренә лаек кызлар тәрбияләде, дигән фикердә:

– Мөдәррис аганы якыннан аның кызы Айсылу аша белдем. «Сәләт»тә танышып, Мәгариф министрлыгында эшләгән чорда шушы гаиләнең министрлык өчен никадәр хезмәт куйганлыгын күрдем. «Мәгариф» нәшрияты әдәбият, тел китаплары чыгарды. Бу эш әле дә дәвам итә.

Язучы, журналист Гөлүсә Закирова М.Вәлиевне иң зур остаз дип атый:

– Мөдәррис абыйның кызы Айсылу белән бик дус идек. Мөдәррис абый миңа да әти кебек булды. Мөдәррис абый – редакторлык эшенә дә остаз булган шәхес.

Мөхәррир Нурзидә Нотфуллина һәм Кадрия Фәйзрахманова М.Вәлиев белән «Мәгариф» нәшриятында бергә эшләгәннәр. КФУның татар тел белеме кафедрасы доценты, дәреслекләр авторы Рамилә Сәгъдиева М.Вәлиев булышлыгы белән байтак китапларны дөньяга чыгарган. КФУ профессоры, әдәбият галиме Фоат Галимуллин да М.Вәлиевне нашир буларак зурлый:

– Ул фәннәр кандидаты иде, мәктәпләр өчен дәреслекләр чыгарган вакытта аның галимлеген тоеп яшәдем. Мәсәлән, безгә Гаяз Исхакыйны дәреслекләргә кайтарырга – беренче булып әдәбият дәреслекләренә кертергә туры килде. Программа буенча Исхакыйга 6 гына сәгать каралса да, Мөдәррис белән киңәшкәч, 7 нче, 10-11нче сыйныф дәреслекләрендә Исхакый иҗатына яңадан урын бирдек.

Драматург Данил Салихов М.Вәлиевнең Әмирхан Еникидән әчкерсез елмая белүен һәм галимлеген искә алды, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан М.Вәлиевнең исемен мәңгеләштерү өчен нәшриятлар чыгарган иң зәвыклы китапларга аның исемендәге премия булдырырга кирәклеген әйтте, филология фәннәре кандидаты Рәсимә Шәмсетдинова Әлки районында М.Вәлиев укыган Алпар гомуми урта белем бирү мәктәбенә аның исемен бирергә чакырды.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА,
intertat.tatar

СЕЗ КЕМНӘР?

Сез кемнәр, сез кемнәр, сез кемнәр?
Сихерле киртәме юлларда?
Томаннар аша без үреләбез
Көрешергә үрелгән кулларга.

Абынган, егылган чак була,
Барысын аңлыйсыз, күрәсез.
Ялына ут капкан толпардан
Кул сузып, төшләргә керәсез.

Ничәмә мәртәбә бит инде
Киләчәк өчен сез янасыз!..
Без юлга чыкканда,
кул болгап,
Ялкыннар эчендә каласыз!..

...Шартлаулар, янгыннар яктыртса,
Барыбер караңгы ул төннәр...
Шул төндә яндыгыз, туганнар,
Менә бит сез кемнәр, сез кемнәр...

Янды тән, янды кан – җан калды,
Шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың? –
Без кемнәр, без кемнәр, без кемнәр?!

Зур серләр ачсак та – без кемнәр?
Галәмгә очсак та шул сорау!
Илләрдән китсәк тә, кайтсак та,
Ярларны кочсак та – шул сорау!..

...Төшләргә керәсез, күрәсез:
Шул юлда безнең дә гомерләр.
Меңләгән күз карый бу чорга:
– Сез кемнәр, сез кемнәр?
Сез кемнәр?!

МУЗЕЙ АЧТЫМ...

Мин гаҗәеп музей ачтым.
Анда
Фатих Кәрим язган каләм бар.
Мин өр-яңа музей ачтым.
Анда,
Кутуй кайта, диган хәбәр бар.

Минем музеемда Мөҗәйләрдән,
Алишлардан яңа хатлар бар.
Анда Җәлил ярсып шигырь укый!
Ә янында...
аның башын кискән балта бар.

Музеемда –
канәфер чәчәкләре,
кашкарыйлар,
кыргый гөләпләр.
Ядрә тишеп үткән йөрәкләр бар,
Үтерелгән җырлар,
теләкләр...

Музеемда – каен тузы түгел –
ә кешеләр янган мичләр бар,
һәм солдатлар сөйгән хатыннарын
соңгы тапкыр кочкан кичләр бар...
Ярсу хисләр, бетмәс үчләр бар!..

Табалмассыз ләкин ул музейны,
житсәгез дә җирнең читенә...
Яңа музей – минем йөрәгемдә,
килегез сез аңа,
Кешеләр!..

* * *

Далаларга чыга, урманнарга, —
кая гына илтми сукмагым!..
Ничә тапкыр сәлам әскертләрен
туган йортым итеп йокладым.

Менә бәет кебек моңлы урман,
менә җырдай иркен кырларым…
Кояш монда таңнан торып үпкән
әбиемнең айдай урагын…



Фәннур САФИН

Һәм син белгән яшерен бер сукмактан,
бәлки, мин дә инде үткәнмен;
Язмышымның кара мизгелләрен
Такташчалап, бәлки, сүккәнмен.

Көннәремнең яктылары әнә
мәңгелеккә керә хәтергә.
Ул хәтернең ничек уянуын
язган безгә җырлап әйтергә.

Минзәләдә туып-үскән, диләр,
Малтабарыңнан син, мин – Күзкәй.
Бикбау, Таулар яки Байлар булсын, –
Алар миңа хәзер бер сүздәй.

Минзәләдән лә мин, Минзәләдән,
«Мин» сүзеннән бит ул башлана,
Борып булмый аны башкага! –
Тарих белә ләса, күпме исем
таккан язмыш безнең башларга!

Һәм гүзәлен сагынып
Минзәләнең,

Кышын бишмәт алып кайтыр диеп,
Көтеп карадым мин, уңмадым.
– Әткәң шахтада ул... – диде әбкәм,
Тик ул
Кеше кайтыр шахта булмады...

...Янда булсаң, сабый, кочагымнан
Бер дә чыкмас идең, мөгаен.
Чиксез иркен Хыял галәмендә
Бергә очар идек көн саен.

– Кай тарафта ата булыр кеше,
Үзе кайда, җаны кайларда? –
Шулай уйлыйм
Төнне айкап сабый үксүләре
Бәгыремне телгән арада.

ОҖМАХ

Безне юллар очраштырды
Көндез түгел, кичкырын.

Кулын болгап шул ук ак каеннар Карап калыр безнең киткәнне...

(Танылган шагыйрь Фәннур Сафинның туына 75 ел)

«Әйдә биик?» дип үз телләрендә
ромашкалар кулга сузыла.
Аh, гүзәлләр нинди охшаганнар
ак калфаклы болгар кызына!..

Таң сызамы җанга ал нурларын,
йә барамы кояшның баеп, –
матур! илнең газиз табигате.
…Юк, башкача уйлау да гаеп!..

ҖЫРЧЫ

Илһам Шакировка

Салкын акыл белән кайнар йөрәк,
Имән белән давыл алыша.
Мәңгелек гамь белән битарафлык,
Дулкын белән дулкын ярыша.

Корылык белән яңгыр тамчылары,
Ашлык белән ачлык тартыша.
Көн корабы баткач төн-диңгезгә,
Төн җиңдем дип ләкин ялгыша...

Төн диңгезен кичеп чыга кояш,
Яшәү белән үлем сынаша...
...Башын тоткан җырчы:
Ничек барын
Сурәтлим, дип, гади җыр аша?!

МИНЗӘЛӘДӘН

Рәшит Гәрәйгә

Минзәләдән, диләр дә бит безне,
Син – Малтабар юкса, мин – Күзкәй.
Хет Тәкермән булсын, алар миңа
ераклашкач хәзер бер сүздәй.

Минем өчен бер сүз – «Минзәлә» бар,
Сиңа «Бар!» ул миннән дә артык.
Син Казаннан ешрак качасың шул,
Минзәләне күбрәк яратып.

Минзәлә дә һаман сине даулый,
Синнән башка яши алмый ул.
Җәен сагына сине яшел сукмак,
Кышын сагына сине карлы юл.

Уйланам да, җаным өзгәләнә,
Таң чыклары куна күзләргә.

Туар таңнар өчен борчылыпмы
ал томанда ята Минзәлә.
Таң чыклары куна шулчак,
Таң чыклары куна күзләргә.
Таң чыклары...

КЕШЕ ЮЛГА ЧЫКСА...

Кеше юлга чыкса,
икмәк телеп
калдыра, ди, ишек өстендә.
Аннан инде ничек кайтмый калсын,
аны монда ризыгы көтсен дә!..

Барыр юлым уңа күрсен, дисә,
ниятләре булса изгедән,
юлчы үзе белән
бер уч туфрак
алып китәр туган нигездән.

Юлчыларны илдән халык шулай
йолаларны бозмый озата.
Шуңадырмы, ирләр кайталмаса,
илләр гизеп,
моңлы җыр кайта!

СИН ЕЛЫЙСЫҢ...

Мин ишетәм сине, гел ишетәм,
Иртән, йә булмаса, кичкырын,
Хәтта төнлә...
Син елыйсың, сабый,
«Әткәм, әткәм!..» диеп кычкырып.

Әллә соң бер генәң – әнкәең дә
Кайтмаска дип чыгып киттеме?
Шушы сагыш, йөрәк түзмәс сагыш
Садә күз яшьләрең түктеме?

Син елыйсың, сабый...
Әткәм назын
Тоя алмый үстем үзем дә.
Назсыз үтте көтү көткән җәйләр,
Нурлы язым, ачы көзем дә.

Шатланыпмы, шаярыпмы:
– Куып җит! – дип кычкырдың...

Әңгерләрдән зәңгәрләнгән
Кырларга йөгердек без,
Дөньяның шушы почмагын
Оҗмах итеп күрдек без.

Кояштай якты бәхетне
Кызганып түгел бер дә,
Качтык икәү онытылып,
Качтык иң аулак җиргә.

Планеталар кавышкандай,
Куллар кулны алганда,
«Өзеләм!..» дип тирбәлделәр
Нәни кыргый алмалар...

Сүзләр түгел, күзләр иде
Аңлашу чаралары.
Яшералмый иде серне
Хәтта төн каралары.

Хәзер белдек, соңлап белдек,
Чын мәхәббәт булган ул.
...Ялгыз барам...
Сагышымнан
Уянмасын дип авыл...

САГЫНАМ

Мин дәүләтсез падишадай булам
читтә ялгыз калган чагымда.
Кояшларга карап елмаям мин,
Сары айга карап сагынам...

Тентүләрдә туздырылган йорттай
тәртипсез уй түгел башымда, –
Ераклардан җәһәт кенә килеп,
Син торасың кебек каршымда!

Мин каладан авылыма таба
сузылып киткән юлга күз атам.
Тәрәзәмне ачып, уйларымны
туган якларыма озатам...

Ак күгәрчен булып оча хыял
Иң бәхетле узган чагыма.
...Кояшларга карап елмаям мин,
Сары айга карап сагынам.

Башкортстанда туган татар Геройлары

(Ахыры. Башы 23 нче санда).

Дәйләгәй (Дәүләтгәрәй) Ногманов – Ишембай районының Түбән Әрмәт авылыннан. Танк взводы командиры. 1944 елның 13 октябрендә Польшадагы Михалув бистәсен азат иткәндә әүвәл үзе генә дә дошманның 4 танкын яндыра. Аннары машинасына ут капкач, рычаглар артына үзе утырып, дошманның «Пантера» танкы өстенә юнәлә һәм, шартлап, һәлак була.

Талип Нөркәев – Бакалы районының Үстем авылыннан. 1944 елның апрелендә Днестр елгасын кичүдә батырлыклар күрсәтеп танылa. Сугыштан соң Октябрь, Туймазы калаларындагы нефть промыселларында эшли.

Михаил Петров – Бакалы районының Иске Сарашты авылыннан. Мөгаен, керәшен татарыдыр; ул мин туган Байсар авылында 1925 еллар тирәсендә монтер булып эшләгән. 1926 елда ук армия сафларына чакырылган, сугышны авиаполк командиры булып, подполковник дәрәҗәсендә каршылаган. 1944 елда Беларусьны азат итү өчен көрәшкән. 1945 елның 24 мартында Герой исеменә лаек булган. 1954 елга кадәр полковник дәрәҗәсенә ирешеп, Винница каласында эшләгән, шунда 1967 елда вафат булган.

Габделхәй Сәетов – Балтач районының Төкән авылыннан. Сугышка кадәр Тәтешле районындагы Чыргылды авылында эшләгән. Икесе дә – татар районнары. Фронтта Г.Сәетов взвод командиры булып йөри, сержант. Берлинны штурмлаган чакта командиры сафтан чыккач, взводны үзе һөҗүмгә күтәрә һәм Шпрее елгасын уңышлы кичеп, плацдарм яулый. Сугыштан соң янә Чыргылды авылына кайта.

Нурулла Сафин – Аскын районының Иске Казанчы авылыннан. 1945 елның гыйнварында Одер елгасын кичеп, Польшаның Ополе каласын дошманнан азат итүдә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң колхоз рәисе урынбасары, авыл советы рәисе булып эшли. Бүген Иске Казанчыдагы мәчет аның исемен йөртә.

Шәриф Сөләйманов – Краснокама районының Яңа Каенлык авылыннан. Сугышка кадәр Чакмагыш районында эшли, аннары хәрби училище тәмамлый. Сугыш башлангач, танкларга каршы артиллерия полкының 1 нче батарея башлыгы була. 1943 елның ноябрендә капитан Сөләйманов Гомель өлкәсен азат итүдә батырлык күрсәтә, бер айдан соң Герой исеменә лаек була. Сугыштан соң Кушнаренко райкомының беренче секретаре, Чакмагыш районының башкарма комитет рәисе, Башкортстанның финанс министры булып эшли.

Муллаяр Сыртланов – Бүздәк районының Сыртлан авылыннан. Сугышка кадәр Актаныш районы күчмәннәре 1860 елларда нигезләгән Турбаслы (Благовещенск районында) авылында эшли. Сугышта Днепр елгасын кичүдә танылa, үз отделениесе белән дошманның 8 танкын юк итә, әмма яуда үзе һәлак була, аңа 1944 елның 23 февралендә Герой исеме бирелә. Яртылаш акталышлылардан хасил Иске Турбаслы авылында бүген аның исемендәге урам бар.

Мәгубә Сыртланова – Бәләбәй шәһәреннән. Балашов каласындагы очучылар мәктәбен тәмамлый. Сугыш барышында 780 хәрби очыш ясый. 1945 елның 26 март төнендә Германиянең Данциг каласында дошманның артиллерия батареясын юк итә. 1946 елның 15 маенда аңа Герой исеме бирелә. Сугыштан соң Казанда яши, «Электроприбор» заводында контролер булып эшли.

Миргай (Миркәй) Фәрхетдинов – Шаран районының Яңа Каряуды авылыннан. Совет-фин сугышында катнаша, сугышка кадәр кече лейтенантлар мәктәбен тәмамлый. Сугыш башлангач, өлкән лейтенант була, пулеметчылар ротасын җитәкли. 1944 елның мартында Көньяк Буг елгасын кичеп, Украинаның Николаев өлкәсен азат итүдә батырларча яу кыла, әмма һәлак була.

Әнвәр Фәтхуллин – Иске Бүздәктән. Аэроклуб һәм Свердловск очучылар мәктәбен тәмамлый. Эскадрилья командиры урынбасары капитан Фәтхуллин җитәкләгән төркем Польшаның Токорня каласы янында дошман оборонасын өзүдә танылa, 1945 елның гыйнварында Әнвәр Герой исеменә лаек була. Сугыштан соң да хәрби хезмәттә кала, полковник дәрәҗәсенә ирешә.

Әмир Хәйдәров – Тәтешле районының Югары Кодаш авылыннан. Сугышка кадәр колхоз рәисе, авыл советы башлыгы булып эшли. 1943 елның сентябрендә Днепр елгасын кичүдә һәм Гомель өлкәсен азат итүдә танылa. Сугыштан соң колхоз рәисе, өлкән урманчы булып хезмәт куя.

Гайнанша Хәйдәршин – Яңавыл районының Байхуҗа авылыннан. Әтисенең гаиләсе белән бергә, кулаклыкка чыгарылып, сөргенгә сөрелгәндер, ул 1930 елларда Магнитогорск металлургия заводын төзүдә, дүрт елдан соң Пермь каласының пристанендә эшли. 1943 елның октябрендә Днепрны кичүдә, Украинаның Кременчуг каласын азат итүдә батырлык күрсәтә. Алтын Йолдызны аңа маршал Жуков тапшыра. Сугыштан соң кайтып, Герой-ветеран Байхуҗа сельпосын һәм колхозны җитәкли.



Сафа Хәсәнов – Стәрлебаш районының Өметбай авылыннан. 1942 елда кече лейтенантлар мәктәбен тәмамлый, 16 нчы гвардия кавалерия дивизиясенең минометчылар взводы командирына әверелә. 1943 елның 27 сентябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә, аның взводын немец автоматчылары уратып алган була, ә совет солдатлары бәжрага тупланып, аларны үзләре яулаган плацдармга якын җибәрмичә тота. Сугыштан соң Сафа ике колхоз рәисе, Стәрлебаш һәм Сайран авыл советы башлыгы булып эшли. С.Хәсәновның исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасына кертелгән.

Габдулла Шаһиев – Краснокама районының Яңа Кабан авылыннан. Сугышка кадәр Уральск каласында, аннары Таҗикстан белән Төрекмәнстанда яши. Сугыш юлын 61 нче кавалерия дивизиясендә пулеметчы булып башлый, ә 1943 елның гыйнварында 112 нче Башкорт дивизиясенә күчерелә. 1943 елның октябрендә Беларусьның Гомель өлкәсен азат итүдә батырлык күрсәтә, Герой исеме 1944 елның 15 гыйнварында бирелә. Сугыштан соң Төрекмәнстанның Чәрҗәүгә районында склад мөдире булып эшли башлый. 1956 елда тикшерү үткәргәндә, аның складында 179 мең сумлык җитмәүчелек ачыклана. СССР Югары Советы президиумының 1959 елгы указы нигезендә, Шаһиевне Герой исеменнән мәхрүм итәләр һәм 12 елга төрмәгә озаталар. Азат ителгәч, ул Үзбәкстанның Навои өлкәсендәге Зарафшан каласына кайта. 1976 елда Зарафшан шәһәр суды карары буенча элекке хөкем карары юкка чыгарыла. Габдулла 1984 елда Сарапул районының Сигай авылында төпләнә, аннары Краснокама районының Яңа Кабан авылына кайтып китә. 1992 елда Россия Президенты указы нигезендә аңа Герой исеме яңадан кайтарыла. Менә шундый сират күперләре кичкән каһарманның исеме 112 нче Башкорт дивизиясенең мемориаль тактасында да урын ала.

Миңневәли (Миңнегали) Шәймөратов – Кырмыскалы районының Биштәкә (хәзер Шәймөратов) авылыннан. Гражданнар сугышы елларында Блюхер армиясендә йөзбашы. Аннары Казанда кавалерия мәктәбендә уку, армиядә хезмәт. 1934 елда Төркиядә хәрби атташе, Кытайда хәрби киңәшче була. Сугыш башлангач, Мәскәү үзәген саклаучы кавалерия полкы башлыгы. 1941 елда Уфада 112 нче Башкорт дивизиясе төзелә башлагач, полковник Шәймөратов 10 декабрьдә аның командиры итеп билгеләнә, 1942 елда генерал-майор дәрәҗәсенә лаек була. Сталинград янындагы канкоюлы яулардан башлап, Украинага кадәр сугышчан юл уза. 1943 елда Луганск каласы янында чолганышка эләккәч, дивизияне шуннан алып чыгу өчен, үзе беренче булып һөҗүмгә ташлана, батырларча һәлак була. Аның дивизиясеннән 78 кеше Советлар Союзы Герое исемен яулый. Шәймөратовның үзенә Россия Президенты Указы нигезендә 2020 елның 30 мартында «Россия Каһарманы» дигән исем бирелә.

Гыймай Шәйхетдинов – Нуриман районының Кызылъяр авылыннан, ә бу авылга дистәләгән һәм йөзләгән булып, Актаныш районының Җияш, Җизмыек авылларыннан 1742-1743 елларда ук татарлар күченеп килә, 1860 елларда, «башкорт»лыкларын саклап калу һәм 40 ар дисәтинә имана җире эләктерү өчен, шул ук Актанышның Шәбез авылыннан – 421, Исәнсефтән – 129, Аештан – 83 кеше, аларга өстәлеп, Әнәк, Илтимер, Качкын, Усы, Карач авылларыннан да дистәләгән татар күченә. Гыймай сугышка кадәр Уфа урман технологиясе техникумын тәмамлый, Нуриман районы үзәгендә Осоавиахим башлыгы булып эшләргә өлгерә. Сугыш башында артиллерия училищесын тәмамлый, фронтка 1944 елның гыйнварында гына барып эләгә. Әмма февраль аенда ук Украинаның Черкассы өлкәсен азат иткән чакта 250 фашистны юк итеп, Гыймай җитәкләгән батарея бәжра эченнән чыга. 1944 елның сентябрь аенда Гыймай инде Герой исеменә лаек була. Сугыштан соң Нуриман районында ДОСААФ комитетын һәм саклык кассасын җитәкли.

Үлмәс Шакиров – Балтач районының Асау авылыннан. Өлкән сержант Шакиров взводы Беларусьның Витебск каласын азат итүдә танылa. Дошманның өч һөҗүмен кире кагудан тыш, алар әле разведка отрядын да кулга төшерә. Сугыштан соң колхоз рәисе булып эшли, мәктәптә укыта.

Назыйм Якупов – Кушнаренко районының Карача-Елга авылыннан. 1956 елда Будапешт каласында кузгалган азатлык хәрәкәтен бастыруда катнаша, шул ук елда Герой исемен ала. Одесса һәм Мәскәү университетларында укыта, тарих фәннәре докторы дәрәҗәсен ала.

Шаһи Җамалетдинов – Белорет районының Шыгай авылыннан. 1945 елның 18 апрелендә Чехословакиянең Брно шәһәрен азат иткәндә укчы Шаһи дошманның ике танкын һәм өч тубын юк итә, 1946 елның 15 маенда Герой исеменә лаек була.

Уфа галимнәре Башкортстан геройлары дип керткән исемлектә Чиләбе өлкәсенең Кунашак (элекке Аргаяш) районыннан Газиз Мирзагалимов, Гаяз Баймурзин, Бари Солтанов исемнәре дә бар. Кунашак халкының яртылаш рәвештә татарлардан хасил булуын бик яхшы беләбез, ләкин барча авылларының да татарныкымы яисә башкортныкымы икәнен аермачык әйтә алмаганга күрә, бездән төгәлрәк белүчеләр хозурына калдырабыз. Шулай ук, мин фәкыйрегезнең Башкортстанның Күергазы, Хәйбулла районнарына да барып җитә алганы юк, шул сәбәпле Кинҗә-Абыз авылында туган Гафиатулла Арсланов белән Сәлман Биктимеров, Карайдан Хәсән Гайсин, Иске Мурапталдан Морат Хуҗаков, Кара-Көчек авылыннан Каюм Әхмәтшинны да татарлар исемлегенә теркәүдән тыелабыз.

Вахит ИМАМОВ.

Халык һәм җыр – аның үткәне

(Венера Гәрәеваның тууына 80 ел)

Венера Гәрәеваның 50 еллык юбилей кичәсендә шундый сүзләр яңгыраган иде: «Венера – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең вөҗданы һәм йөз пакьлеге». Чын күңелдән әйтелгән бу сүзләрдә дөреслек бар. Венера Гәрәева – ансамбльнең данын, намусын ил алдында аклаучы, аны кадерләп саклаучы да. Чын мөселман гаиләсендә туып, 13 яшьтән Минзәлә драмтеатры гаиләсендә үсү аның характерында дөньяга, сайлаган һөнәренә, милли музыка сәнгатенә зур мәхәббәт һәм намуслы караш тәрбияли.

Чынлап та, хор җитәкчесе булу, бигрәк тә милли ансамбльдә, үз милләтенә зур мәхәббәт, аның телен нигезенә кадәр белү, хөрмәтләү, ничә гасырлар буе иҗат ителгән шигъриятен, моңын, көйләрен аңлау гына җитми, аны башкара белү осталыгын да, белемең дә, сайлап ала торган интуициян дә булырга тиеш. Бу билгеләр барысы да Венера ханымда туплана, аны татар җыры, шигъриятенең энциклопедиясенә әверелдерә. Никадәр җырлар, хор өчен эшкәртелеп, яңача яңгырашта татар халкына кире кайтарылды, яңа буын алар белән очраша, аларның моңын татый алды, милләт, сәнгать өчен үзен сайлаган бу һөнәрдә, шуннан да зур бәхет бармы икән! Нинди генә илдә булса да, нинди конкурсларда катнашса да, ансамбльнең хоры, солистлары, һәрвакытта алдынгы урыннарда, бу – аның иҗат җимеше.

Ул дөньяга Чулпан йолдызыдай
Балкып килгән иде бер таңда;
Пәйгамбәрдәй изге бабасыннан
Якты рухлар иңде бу җанга!
Җыр яратты – үз татары өчен
Моңга күмәр иде дөньяны!..
Халык һәм җыр, сәнгать,
ил гамьнәре –
Бары шулар аның үткәне.

Шагыйрә С.Гәрәева бу юлларны юкка гына В.Гәрәевага багышлап язмагандыр…

Венера Хәсән кызы Гәрәева 1943 елның 25 июнендә Саба районы Өчиле авылында туа. Унөч яшенә кадәр әбисе белән бабасында тәрбияләнә. 1956 елда әти-әнисе янына Минзәлә шәһәренә күчеп килә. 1960 елда ун классны тәмамлагач, Казан музыка училищесына кереп карый, тик хәзерләреге булмау сәбәпле, аны алмыйлар. Бу хыял бары тик 1964 елда гына тормышка аша. Ул 1960 елда Алабуга шәһәренең культура-агарту училищесында укый башлый.

1961 елда, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә яшь кадрлар җыю өчен, аның сәнгать җитәкчесе Җәүдәт Айдаров Алабугага килә һәм аннан өч кешене, шулар арасында В.Гәрәеваны да ансамбльгә алып китә. Бу – Венераның зур милли сәнгать юлына басуының беренче адымы була.

Ансамбльнең 1961 елгы репертуарын А.Ключарев музыкасына Ф.Гаскәров куйган «Тула өмәсендә» дигән җырлы-биюле күренеш баета. Гади авыл кызы милли сәнгатькә бар тормышын биргән ансамбльнең корифейлары белән беренче мәртәбә очраша. Алар – Р.Тимерханова, Г.Гафиатуллина, Г.Шаһиев, З.Әхтәмова, С.Йосыпов һ.б., шулай ук бөек композиторларыбыз А.Ключарев, З.Хәбибуллин, Ә.Бакиров, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи һ.б. Шул ук елда беренче гастрольләр Урал-Себер, Ерак Көнбатыш, Мәскәү, Ленинград шәһәрләрендә була, беренче мәртәбә зур сәхнәләр белән танышу башлана. Беренче очрашудан ук ансамбльгә булган мәхәббәт, җырга-моңга тугрылык аның яшәеш максатына әверелә. Шушында дирижерлык профессиясен беренче күрүенә карамастан, бу һөнәр аның мәңгелек мәхәббәтенә әйләнә, һәм ул аңа соңгы көненә кадәр турылыклы булып кала.

1961-1964 ел дәверендә ансамбль Сахалинда булырга өлгерә, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Ерак Көнчыгыш, Архангельск, Мурманск – кыскача әйткәндә, элекке СССР илләрен берничә мәртәбә әйләнеп чыгарга туры килә. Шул вакыттагы хор җитәкчесе Җ.Котдусов аның укырга теләге барлыгын тоеп, Казан музыка училищесына – хор белән җитәкчелек итү бүлегенә әзерли, һәм, уңышлы имтиханнардан соң, 1964 елда В.Гәрәева шушы бүлектә Г.Хәмзина классында укый башлый. Уку дәверендә дә аңа ансамбль белән гастрольләргә барырга туры килә. Училище киләчәк профессия өчен, репертуар мәсьәләсендә дә, техника мәсьәләсендә дә терәк була.

1968 елда училищены тәмамлагач, аны Саба музыка мәктәбенә укытучы һәм Саба халык хорына җитәкче итеп юллыйлар. Шул ук елда В.Гәрәева Казан дәүләт консерваториясендә, Ә.Абдуллин классында укуын дәвам итә. 1972 елда, ансамбльдә милли җитәкче кадрлар җитмәү сәбәпле, В.Гәрәева Казанга кайта һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хор җитәкчесе булып эшли башлый.

Соңгы елларда Җ.Айдаров белән Җ.Котдусов ансамбльдән китү сәбәпле, 70 нче еллар башында коллектив җитәкчесез кала. Ул елларда сәнгать җитәкчесе булып А.Ключарев та, Ә.Абдуллин да эшләп ала, ләкин коллектив яшь көчләр таләп итә. Бу чорда ансамбльнең яшь солистлары Н.Василова, Ш.Әхмәтҗанов, М.Садыйков, М.Зәкиевалар өчен репертуар мәсьәләсен хәл итү һәм ансамбль өчен зур җырлы-биюле күренешләр хәзерләү кирәк була.

1971 елдан ансамбльгә хор җитәкчесе булып Л.Кустабаева килә, һәм киләчәктә ул, сәнгать җитәкчесе булып, утыз елга якын, Р.Мостафин – оркестр җитәкчесе; Р.Гарипова – балетмейстер, В.Гәрәева – хормейстер, бергәләп, ансамбльнең профессиональ дәрәҗәсен тагын да биеккә күтәрү өчен эшли. Иң беренче бурыч – булган солистлар белән ансамбль репертуарындагы алтын фондны күтәрү. Нәтиҗәдә ансамбль репертуарында күп әсәрләр яңадан туа. С.Габәши музыкасы, Ә.Ерикәй сүзләре, А.Ключарев эшкәртүендә «Кәккүк», шул ук Ключарев эшкәрткән башкорт халык көе «Зөлхиҗә», татар халык көйләре «Зөбәрҗәт», «Кара урман» һ.б. Шулай ук В.Гәрәева килгәч, бу яшь солистлар белән яңа язмалар эшләү башлана. Ансамбль соңгы еллардагы авыр торгынлыктан күтәрелә.

1972 елда өч айга якын Урал-Себер маршруты нәкъ 1961 елдагы кебек үк кабатлана. 1972–1974 елларда консерваториядәге уку эш белән бергә бара. Бу – ансамбльнең иң күп гастрольләрдә йөргән еллары. Шулай өч-дүрт ай юлда үтә – көз көне чыгып кителә дә, яңа елга гына кайтыла.

Ел саен ансамбль Мәскәүнең төрле залларында концертлар куя, 1977 елда Мәскәү ансамбльгә Туниска – Бөтендөнья җыр һәм бию ансамбльләренең конкурс фестиваленә барырга фатиха бирә. Бу фестиваль 11-29 июльдә була. Ансамбль «Аулак өйдә» программасын һәм концерт программасын алып бара. Бу елларны ансамбльгә яшь көчләр килә. Л.Бичарина, Ә.Хәйдәров, Н.Вәлиева, Г.Әмирҗанов һ.б. – барысы да шушы составта була.

Аларның музыкаль әзерлекләре булмау сәбәпле, В.Гәрәева бу яшьләргә музыка грамотасын өйрәтә һәм алардан солистлар ясый башлый. Берничә елдан яшьләрнең күбесе, В.Гәрәева ярдәмендә Казан музыка училищесының җыр бүлегенә укырга кереп, дипломлы җырчыларга әверелә.

Тунистагы Карфаген фестивалендә ансамбль лауреат исеменә лаек була һәм фестивальдән соң тагын бер ай буе Тунис буйлап гастроль сәяхәте үтә. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе итеп 1978 елда Л.Кустабаева куела.

1978 елның февраль аенда РСФСР җыр һәм бию ансамбльләренең беренче конкурсы үткәрелә. Татар җыр һәм бию ансамбле Карелия (Кантеле) коллективы белән икенче урынны бүлешә. Беренче урында – комилар, удмурт һәм чуашлар.

1978 елның июнь аенда ансамбль, Италия һәм Мальтадан гастрольләрдән кайткач, Кавказга бара һәм чит ил туристларын милли сәнгать белән таныштыра. Бу елларда хор группасы Ә.Абдуллинның күп әсәрләре белән баетыла. «Сорнай моңы», «Картуф», «Җомга», «Әрбет», «Әзифә», «Тәчкә икә», «Сандугачкай», «Зәңгәр чиләк» һ.б. – шундыйлардан.

80-90 нчы елларда ансамбль өчен композитор Р.Гобәйдуллин тарафыннан Япония гастрольләре өчен язылган «Ай, былбылым» Н.Исәнбәт сүзләре, Тохоета Тоясаки сүзләре һәм көе – «Ел фасыллары», татар халык көйләре «Яшь таллар», «Авыл егете», «Усаккайлар» һ.б. була. Композитор М.Шәмсетдинованың шул елларда куелган «Корбан бәйрәм» һәм «Рамазан» программаларында да хорга зур урын бирелә, төп эчтәлек хор яңгырашы белән ачыла.

2000 елда ансамбль программасы яңа әсәрләр белән тулыландырыла. Болар – хор өчен Н.Гәрәев эшкәртүендә себер, әстерхан, керәшен, кырым татарлары, татар-мишәрләр җырлары. Ансамбль үз репертуарында гастрольләрдә булган һәр илнең җырларын саклый. Кайвакытта хормейстерга бер төн эчендә шушы илләрнең җырларын, гимннарын яттан өйрәнергә туры килә.

В.Гәрәева, хормейстер буларак, Татарстан республикасының 60 еллыгына багышланган, Р.Яхин музыкасы, татар шагыйрьләренең шигырьләренә «Туган илем» циклын, Р.Харис сүзләренә Р.Гобәйдуллин музыкасы – беренче татар конгрессына багышланган, симфоник оркестр һәм хор өчен язылган «Татар иле» кантатасын башкара.

1979 елның январь-февраль айлары Африка илләренә сәяхәттә үтә. 1980 ел башыннан ук «Сабантуй» дигән җырлы-биюле зур программага әзерлек башлана. Шулай ук июнь аенда булачак Каракалпакстан республикасында үткәреләчәк татар декадасына ансамбль яңа программа эшли. Казан шәһәренең бөтен иҗат коллективлары да катнашкан зур масштаблы декададан соң, сентябрь аенда В.Гәрәева Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исемгә лаек булды.

1986 елның 19 мартында Мәскәүнең Колонналар залында М.Җәлилнең 80 еллык юбилее үткәрелә. Р.Яхин музыкасы, М.Җәлил сүзләренә язылган «Җырларым» әсәрен симфоник оркестр белән ансамбльнең хор группасы башкара. Бу ел ансамбль өчен зур вакыйгаларга бай ел була. Апрель аенда Г. Тукайның 100 еллык юбилеена да ансамбль зур өлеш кертә. Шушы ук елны РСФСР җыр һәм бию ансамбльләренең икенче конкурс фестивале программасын Мәскәү комиссиясе яратып кабул итә. Март аенда Мәскәүгә китәргә өч көн кала Химиклар мәдәният сараенда программаны тагын карыйлар һәм үзгәртүләр кертәләр. Культура минстрлыгы чыгышны партия турындагы җырлар белән ачып җибәрергә куша. Конкурста ансамбль беренче урынны ала.

Аннан соң ансамбль Япониягә бару өчен яңа программа әзерли. Андагы өч япон җырын хор группасы япон телендә башкара. Коллектив өчен зур җиңү: ансамбль, Татарстаннан беренче булып, Тукай телен японнарга ирештерде, аларны татар җыр-бию сәнгате белән таныштырды; Татарстан җитәкчеләренә ансамбльнең иҗади биеклеген күрсәтте. Япониядәге гастрольләрдән соң, 1987 елның январь аенда В.Гәрәева Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемгә лаек була. 1991 елда ансамбль, филармония составыннан чыгып, аерым коллектив булып яши башлый.

В.Гәрәева 90 нчы еллар башында, җырчы кадрлар әзерләү максатында, Казан музыка училищесында ачылган татар бүлегенә укытучы булып урнаша. Ансамбльнең алтын фондын аякка бастыру өчен яңа яшь кадрлар шунда хәзерләнә башлый, алар турыдан-туры ансамбльгә әзер программа белән солист булып килә. З.Борисова, Д.Имамиев, Ф.Гафиатуллин, Р.Әгъзамова, Ч. Сәлимуллина, А.Җәгъфәрова, Д.Палатова һәм бик күпләрнең солист булып китүендә В.Гәрәеваның роле бик зур.

Филүсә АРСЛАН.

Атнаның сәяси мизгелләре

Тынычлык тәүбәсе

Украинада бара торган хәрби низагны тыныч сөйләшүләр аша җайга салу тәкъдиме белән чыгучы «арадашчы»ларга кытлык моңа кадәр дә булмады кебек. Ә узган атнада инде андыйлар төркем-төркем булып күренгәли башлады һәм, тәкъдим ителгән «тынычлык планы»ның эчтәлегеннән чыгып, алар артында кем торганлыгын да хәтта чамаларга була. Хәлбуки, ошбу четерекле мәсьәләдә риторика, әкренләп кенә, Кремльнең үзендә дә үзгәрә кебек: узган атнада хәрби корреспондентлар белән очрашканда, Россия Президенты В.Путин МХО максатлары турында инде үзе дә, алар агымдагы вәзгыять белән бергә үзгәрә, диде. Әлбәттә, мондый саклыкны аңларга була. Әмма уй-ниятләрдәгегә ачыклыкны гамәли вә мәгънәви адымнардагы үзгәрешләр дә кертә: элегрәк, әйтик, бу мәсьәләдәге кабатланулар «аклану мантрасы»н хәтерләтсә (ә ул, асылда, «МХО ны башлап, без дөрес эшләдек», диюгә кайтып кала иде), узган атнада инде алар «тынычлык тәүбәсе»нә («без беркайчан да тыныч сөйләшүләрдән баш тартмадык» диюгә) алышынды.

АКШ дәүләт секретаре Энтони Блинкен узган атнада Кытайда ике көнлек сәфәрдә булды. Соңгы 5 елда ул АКШның бу илгә сәфәр кылган иң югары дәрәҗәдәге вәкиле санала икән. Сәфәр барышында Блинкен КХР рәисе Си Цзиньпин, тышкы эшләр буенча ККП ҮК комиссиясе канцеляриясе башлыгы Ван И, Кытай тышкы эшләр министры Цинь Ганом белән очрашып сөйләшкән. Ул шулай ук Вашингтонның Тайвань бәйсезлеген якламаячагы турында белдергән. Кытай тышкы эшләр министры Цинь Ган белән сөйләшү 7 сәгать ярым барган. Яклар аның нәтиҗәләрен югары бәяләгән. Ике арада югары дәрәҗәдәге элемтәләр торгызылган, проблемалар да уртага салып өйрәнелгән, аларны хәл итү юллары билгеләнгән, шулай ук ике арада хезмәттәшлек итү өлкәләре дә тәгаенләнгән. АКШ Президенты Джо Байден дәүләт секретаренең Кытайга кылган әлеге сәфәренең нәтиҗәләрен югары бәяләгән, Вашингтон белән Пекинның бүген дөрес юлда булулары турында белдергән.

Инде сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да әйтеп үтик. Россия Украинага Көнбатыштан корал куюны тикшерү өчен, 29 июньдә БМО КШ утырышын үткәрүгә гариза биргән. Бөекбритания белән Швеция Кытайны Россиягә матди-техник ярдәмне күрсәтмәскә чакырган. Франция Президенты Э.Макрон Украинага SAMP/T дигән зенит ракетасы комплекслары китереп җиткерелүе һәм аларның кулланышка әзер булулары турында әйткән. РФ тышкы эшләр министрлыгы Приднестровьедагы Россия гаскәрләренә карата кылынган провокацияләрне Россиягә каршы һөҗүм буларак бәяләячәге турында әйткән. Молдованың Конституция суды илдә эш итә торган Россия яклы «Шор» партиясен законсыз дип таныган. ЕС Украинага 50 миллиард евро күләмендә финанс ярдәме күрсәтүне планлаштырган.

Фоат УРАЗАЙ.

(Дәвамы. Башы 20-23 нче саннарда).

МОСТАФА

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

Ниһаять, иренең тамагы туйды, дегеттәй кара чәйне биш чынаяк эчеп кикереп куйгач, хатын алъяпкыч кесәсендә утлы кисәү булып көйрәп яткан хатны тартып чыгарды. «Жакет кесәсеннән бер кәгазь кисәге килеп чыкты әле, Мостафа», – диде. Гади сүздән генә дә Мостафа сикереп торды, чырае агарды, хатны Халисә кулыннан умырып тартып алды. Ертырга теләде, тыелды, Халисәгә карады. «Кирәкле кәгазьме әллә?» – дип сорады хатын курка-курка гына. «Чепуха!» – диде Мостафа. «Бир, ертып ташлыйм алайса», – диде Халисә кулын сузып. Ул арада баягы хат айныган иренең киң авызлы кесәсенә кереп оялаган иде.

Элгәрерәк елларда, Халисә ире янына төянеп, күчеп килгән дәвердә, юл төшеп мәркәзебез Казанга килгән авылдашлары аларга кагылмый калмый иде. Соңгы вакытларда юл-сукмаклар суынды, суынып кына калмады, тәмам өзелде. Ишетелә, этиләренә кереп кунып та чыгалар, күчтәначләр дә килеп ирешә авылдан, кунак төшә, мәж киләләр. Халисә дә җан иясе, ул гел-гел йөртта бикләнеп утыра алмый, ул сөмсез өй тавыгына әйләнүдән курка! Шуңа күрә иртәләрнең берсендә авылдашлары Ситдыйк килеп кергәч, Халисә бик куанды. Иренең өйдә аек чагы, бусы да бер сөенеч, Халисә авылдаш адәмнәрнең ире, тормышлары хакында ару уйлауларын бик тели иде. Иренең чырае караңгыланган саен, аны яхшы, кунакчыл вә юмарт итеп күрсәтәсе килә иде. Авыл кешесе төпченергә, тозны тел астына салырга гадәтләнгән шул; килеп керә, түргә уза, хәл ала да сорашырга тотына. Мостафаның кайда эшләвен, аена күпме акча төшерүен, ул хәтле сәрмәяне ничек итеп бетерүләрен вәзенләп сораштырганда, Халисәнең тавышы үзеннән-үзе кыркулана. Мостафа ыкы-мыкы утырганда, җәһәт-җәһәт сөйләп үтә. Ире военный заводта, сменалы эштә, шунысы җайсыз, күбрәк төнгелеккә чыга... Элек ашык-пошык тезеп сөйләгәндә, Халисә бик уңайсызлана торган иде, хәзер шома гына алдый, кызарынмый да, ни сорасалар да, бер җавап: ире военныйда...үзе почтада, хаттыр, газета-журналлар тарата, ике кулына бер эш, иртәнчәк урамны бер әйләнә дә күбрәк вакытын өйдә үткәрә, бала-чаганы карыйсы, барлыйсы бар. Ул арада Мостафа онытылып тора, үз эше турында Халисә әллә кемнәргә ярарлык итеп озаклап, тәмләп, һәр фикерен җөпләп сөйләп бирә.

Менә аларның авылында да яңалыклар бар икән. Ит комбинаты ачканнар. Ситдыйк шунда мал суючы булып эшли, имеш. Элек дәүләткә аяклы мал тапшыралар, җәһәннәмгә – Бөгелмәгә тиклем хайваннарны куа китәләр иде. Хәзер суеп, тиресен тунап, ипкә китереп итләй озаталар икән. Ситдыйк хан заманыннан тирә-юньдә мәшһүр сугымчы иде, хәзер комбинатка дәшеп алганнар да өлкән сугымчы иткәннәр. Күчтәначләп килгән Ситдыйк, тормыш рәтен белә, үзе белән бавыр, үпкә-сапка алып килгән, симез-симез кабыргаларны, чалу сөяген дә кыстырган икән. Иртәнге чәйдән соң ул Сорочий базарына юл тотты, соң гына кайтты. «Эх, Казанның сырасы! Хәттин шәп!» – дип мактый-мактый чишенде, талган аякларын Халисә хәстәрләгән җылы суга тыгып утырды. Мостафа төнге сменага эшенә китте, кунакка урын түшәргә дип иелгән хатын урындык артына эленгән күлмәккә шигәеп карады. Күлмәктән аңкыган ис сәерсендерде аны. Сугымчы күлмәгеннән, мөгаен, кан исе киләдер дип фараз кылды. Кунак чишенеп ятып, тиз үк гырлый да башлагач, Халисә оятын яшереп, күлмәкне эленгән җиреннән алып, танавына терәп диярлек, кат-кат иснәде. Бер мәлгә тораташ катты Халисә, күзләренә убыр күренде мени, бугазына әче төер утырды: иренең күлмәк-ыштаныннан еш кына шундый ис килә торган иде! Авырсы ис, куркыныч ис! Склад тирәсендә утыргач, еш кына вагоннарга йөк төяп озатып йөргәч, шикле исләр шуннан ияреп кайта дип белә иде моңарчы Халисә. Ситдыйкның күлмәге аның уйларын башка юлга алып кереп китте, хатынның кулы башка эшкә бармады, ул әле чоланга чыгып керде, әле ишегалдын урады. Төн ката йокысы якын да килмәде Халисәнең, җитмәсә, малчы Ситдыйкның яман гадәте дә бар икән, өй диварларын ишәрдәй гырлый.

Ситдыйк уянды, тәмләп киерелде һәм күлмәген эзләргә кереште. Күлмәге чырае зәңгәрләнгән-күгәргән Халисәдә икән ләбаса!

Иртәнге сый-коймак янында хатын капылт кына сорап куйды:

– Ситдыйк абзый, эшләгән җиреңнең исен Казанга ук алып килгәнсең димме?..

Ситдыйк рәхәтләнеп, теш уртларын күрсәтеп көлеп шаркылдады:

– Бардыр инде, килен! Малчыдан хушбуй исе килмәс! – диде. – Бардыр, бик бардыр. Эшләмәгән көнне сугым сарайлары аша үтсәң дә, мал исе иярә инде ул! Ике көнгә бер мунча да керәм югыйсә. Истән котылып булмый, килен.

Ситдыйк хуҗалардан канәгать булып китте, иртә-кич сыра белән мавыгып, Мостафаның эше, тормышы, көн күрмеше белән кызыксынмады да. Кунакны озаттылар, авылга, күргән-белгәннәргә күчтәначләр тыктылар. Халисә, Мостафа күрмәгәндә генә, шушы соңгы айларда «эшендәге ябык кибеттән алып кайткан» яулык-шәлләрне, күлмәк-күнчекләрне дә тыгып җибәрде. Кичен ирен әзерләп, хәстәрләп эшенә озаткач, Халисә Мостафаның алмаш күлмәк-ыштаннары саклана торган калын тимерләр белән тарттырылган авыр сандык капкачын ачты да эчкә иелде. Керләр арасына мәтрүшкә кыстыра иде Халисә, кат-кат иснәсә дә ят ис тапмады әлегә. Мунчага китте, иренең юарга өлгермәгән күлмәкләрен селки-селки иснәп бакты: Мостафаның күлмәгеннән Ситдыйк исе килә иде. «Известь бушатырга барабыз», дигән төннәрдә кия торган өс-баш кинәмәре утын сараенда эленеп тора иде, Халисә кабаланып, абына-сөртенә шунда барып керде. Сырма җиңнәренә, чалбар балагы очларына, җилкәсенә ак балчык сыланган иде. Халисә киемнәрнең һәр җегең, бөрмәсен бик җентекләп, әнә күзеннән үткәреп тикшерде һәм сырма итәгенә сыланган ак балчык коймаклары тирәсендә көрән-күгелҗем таплар абайлады. Уйлана-исәпли торгач, тапларның канлы эзләр икәнен аерды. Халисә артына тайпылып китте, лып итеп урындыкка утырды, телсез калды...

Дөнья ашыгып үзгәрә, элеккеге эш алымнары күптән беткән, онытылган. Бар иде Черек күлнең тәҗрибәсез, ахмак чаклары, ристаннарны төнлә-төнлә, яңгырда-карда шәһәр читенә, аулакка алып китәләр дә, шундагы әзер чокыр тирәсендә кәнкәйтәләр. Дөрес, тирә-якта боҗра булып өстәмә саклар тора торуын... Шулай да дөньяның мең күзе, мең колагы бар: берәвесе күреп калса, абайласа?.. Дөньяны сасытырга ук базмас, иллә мәгәр, кемгәдер чишәр, шикләрен бүтәннәргә дә җиткерер. «Төнлә мылтык аткан тавышлар ишеттем... әллә кемнедер аттылар инде?..» – дип ычкындырса?..

Шәһәр эчендә сүзләр йөрмиме дип даими тикшереп тордылар, ис китәрлек хәбәрләр таралмады шикелле. Үлемгә хөкем ителгәннәр дә алай ук куркырлык дәрәҗәдә ишле түгел иде әле.

Утыз җиденче елга кергәндә бу «эш»нең һич үзгәрмәс, сыналган, иң ышанычлы дип табылган ныклы тәртибе бар иде инде. Шактый иркен, әмма бик тәбәнәк подвалның идәнендә дәү, калын брезентлар җәяләр дә, җыерчыкларын тигезләп тарттырып куялар. Җыерчыклар арасына кан тулып калса, аны чистарту, арулау шактый мәшәкатьле вә күңелсез эш. Җәлладлар һәрвакыт ашыгалар, ә брезент җыерчыкларын җыештыру күп вакытны ала! Телсез камералардан үлемгә хөкем ителгәннәрне ташып кына торалар, каулап-юрттырып китерәләр. Атып егалар, монысы иң җиңеле, күп вакыт та алмый, дүрткел ишегалдында һичбер вакыт якты төшмәслек караңгы почмакта моторы корбан сорап гөрләп утырган ач машинага мәетләрне оста куллар тиз-тиз ташый, үле гәүдәләр әрҗәгә очып-очып кына куна. Брезент чатыр корылган әрҗә калтырый, аның ихтыярына буйсынып, суынып җитмәгән гәүдәләр дә калтырый, гүя кара язмышларына риза булмаган адәм балалары торып китәргә җыеналар, калкыналар.

Идәнгә җәелгән брезентны ашыгып, бер-берсен каулап чистарталар, ул арада чират көтеп арыган тоткыннарның яңа төркемен куып китерәләр. Черек күлдә чисталыкны яраталар! Тынлыкны да сөяләр! Подвал тирән, бөтен яклар тимер-бетон белән томаланган, дөнья йөзенә чылт иткән тавыш та чыгып җитәчәк түгел. Черек күлдә тавышлар да ныклы бик астындагы тоткын хәлендә.

(Дәвамы киләсе санда.)

Марсель БАКИРОВ

«Чура батыр» дастаны

(Ахыры. Башы 22-23 нче саннарда).

Әлеге җырда да, татар бәетендә дә Чура батыр, Иван IV нең ашап утырган җиренә кереп, аның башын чабып өзгән итеп тасвирлана. Шул рәвешле, төрки халыклар үзләренең хыялында, ягъни уйланма белән үрелгән лиро-эпик иҗатларында булса да, баскак рус патшасын үзләре теләгән җәзага тарттырган.

Казанны алырга кат-кат килүче рус яуларына каршы батырларча көрәшеп йөргән һәм дастан каһарманына прототип Чура исемле реаль шәхес булгандырмы, юкмы – бу сорауга сакланып калган тарихи чыганаклар буенча кистереп кенә уңай җавап бирүе авыр. Дөрес, 1764 елда күчерелгән «Җәмигъ әр-рөмүз» («Серләр җыентыгы») китабына кушымта рәвешендә теркәлгән беренче буыны – Күкәс, икенчесе – Нәрык, өченче буыны Чура исемнәренә туры килә һәм барысы унбер буын тәшкил итә торган шәҗәрә сакланып калганлыгы билгеле. Әмма бу шәҗәрәдә теркәлгән Чураның рус яуларын кайтаруда катнашканлыгы турында берниндә дә мәгълүмат юк. Шулай ук дин башлыгы һәм шагыйрь Кол Шәриф тарафыннан язылган Иван IV нең 1550 елдагы дәһшәтле явын җиңү-түнтәрүгә багышланган «Зафәрнамәи вилаяти Казан» дигән әдәби һәм тарихи-публицистик характердагы әсәрендә дә, гәрчә Казанны саклауда катнашкан күренекле батырлар исемләп аталып чыкса да, алар арасында Чура исеме юк. Казанның һәлакәте һәм татар ханлыгының яулап алынуы белән тәмамланган иң соңгы хәлиткеч сугыш турындагы язма тарихи чыганакларда һәм шул чорга караган истәлекләрдә дә мәркәзне саклауда аеруча зур батырлык күрсәтүчеләрнең һәм каһарманнарча һәлак булучыларның исемнәре берәм-берәм атап күрсәтелсә дә, Чура исеме шулай ук телгә алынмаган.

Югарыда сөйләнгәннәрдән бер мөһим нәтиҗә соралып тора: дастандагы Чура батыр образы, безнеңчә, конкрет бер шәхескә гәүдәләндерүче каһарман түгел, ә җыелма образ булырга тиеш. Аның прототибы, асылда, – Казанны саклап көрәшкән һәм сугыш мәйданында корбан булган дистәләрчә батыр, гомумән, безнең каһарман бабаларыбыз. Чура сүзенең «батыр», «батыр сугышчы» дигән мәгънәсе үзе үк әлеге гомумиләштерү сыйфатына ия булган исем астына төрле каһарманнарны җыю, бергә берләштерү сыйфатына ия. Менә шуңа күрә дә үз балаларының батыр-баһадир булып үсүен теләп, ата-аналарның элек Чура исемен кушарга яратканлыклары һәм Казан ханлыгы чорында, язма чыганаклардан күренгәнчә, андый исемнәрнең шактый булганлыгы бик табигый. Моны шулай ук Чүриле (Чура Иле) яки Чурай дип аталган борынгы авыл исемнәреннән һәм «чура» (колчура, акчура) эпонимыннан ясалган фамилияләрнең шактый таралганлыгыннан да чамаларга була. Чура исемле кешеләр, әлбәттә, Казанны һәм аның тирә-ягын дошман яуларыннан саклаган, әмма исеме тарихи язма чыганакларда теркәлмәгән яугирләр арасында да аз булмагандыр. Җөмләдән, Яшел Үзән районына бәйләнешле «Карауҗа» исемле алда телгә алынган риваятьтә әлеге авылга нигез салган Карауҗаның улының улы Чура батыр «Явыз Иван гаскәрләре Казанны алган вакытта, шушы авыл җирләре өчен сугышып үлгән» дип күрсәтелә.

Ярымлегенда, ярымриваять характерындагы әле телгә алынган текстта берьюлы ике көймәнең койрыгын тотарга омтылу сизелеп тора. Чөнки гаҗәпнең дә гаҗәбе: анда әлеге Чура батырның, алда әйтелгәнчә, баскак русларга сатылып, җәзалап үтерелгән этисенең исеме дә Чура (Чура би). Димәк, сатлык Чура Нарыков прототибына ишарә итә торган Чура бәк тә, шулай ук рус яуларына каршы көрәшеп һәлак булган Чура батыр да – икесе бер үк гаиләдән булып чыга. Икесенең дә бер үк исемдә булуына игътибар итик. Белүебезчә, төрки-татар гаиләләрендә ир баланы, рус гаиләләрендәге кебек, атасының исеме белән атау гадәте беркайчан да булмаган һәм хәзер дә юк. Моннан бу мисал итеп китерелгән ярымлегенда, ярымриваятьтә тарихи Чура шәхесе белән фольклор әсәрләрендә гәүдәләнгән легендар Чура батыр образының ясалма рәвештә бер үк җепкә теркәлгәнлеген, димәк, текстның бары бер Чурага бәйләнешле өлешен генә чыганак итеп файдаланырга мөмкин булганлыгын тану-икърар итү кыен түгел. Кызганыч, «Чура батыр» дастанын тикшерергә алынган фольклорчылар, эклектизм юлына басып, әлеге текстның берьюлы ике өлешенә, ягъни ике версиясенә дә таяна һәм, фикерләрен үзгәртә-үзгәртә, «билгесезне билгесезлек аша» исбатларга тырыша.

Халык иҗатында, фольклор мирасында, билгеле, тоташы белән уйдырмага, фантазиягә корылган, әмма халыкның буйсынмас рухына ятышлы булган катламнар да бар. Мәсәлән, дәүләтчелегеннән мәхрүм калган татар халкы хыялында гына булса да Чураны кабат терелтеп һәм бәет героена әверелдереп, дошманнан үч алдыруы – мөдһиш Иванның башын кистерүе – шуның бер мисалы.. Сәнгати уйланмага һәм халык хыялына нигезләнгән әлеге тасвир руслар Казанны алганнан соң, Сөембикә, имеш, гаскәр җыю өчен манарасыннан аккош булып очып чыгып киткән, дип сөйләнә торган утопик легенда белән шактый аваздаш (әлеге легенда, качып китәргә мәҗбүр ителгән татарлардан күчеп, чуаш фольклорында сакланган). Моннан тыш, элекке Минзәлә кантоның Чураш авылында археограф С.Вахиди язып алган хикәяттә дә Чура батыр исән калган итеп телгә алына. Һәм, Иванга каршы сугышканнан соң, Арча төбәгендә, үз отряды белән килеп, Наласа авылын нигезләве, аннары, күченеп китеп, хәзерге Сарман районында урнашкан Чураш авылына нигез салуы бәян ителә.

Тарихи риваять-легендалар арасында Чура батыр язмышы белән азмы-күпме аваздаш булган Батман батыр турындагы хикәят аерым игътибарга лаек. Чура кебек үк, халык аңында гомумиләштерелгән әлеге эпик каһарман үзенең батырлыкларын Казан алынганнан соң күрсәтә. «Русия патшасы, – диелә текстта, – гаскәр кылып, шәһри Казанны алып әкябирләрнең (бөекләрнең) һәммәсенең башын кистерде. Шуның өчен Казанда кол нәселе дип кылмышлар, олуглардан һич калмаганы өчен. Әмма качкан кемсәләрдән берсе Батман батыр иде. Казан суы артында урманда ат менеп йөрер иде. Бәгъзе вакытларда, Казан эченә кереп, утыз-кырык баш кисеп, дәхи Казан суы артына чыгып китәр иде». Көннәрдән бер көнне су арьягына чыккан «бер марҗа» моны йоклаган хәлендә очрата һәм таш белән бәреп үтерә. Батырның аты, иясенең үлгәнен белгәч, биленнән кабып, аны «Хода теләгән җиргә» илтеп куя. Кяферләр Батман батырның сөяген таба алмый. Бәс, батырның үлеме марҗадан булды, шуның өчен «Батыр үлеме марҗадан» дип мәсәл кылалар».

Ике батырның да үлеме «марҗа»га бәйләп тасвирланганлыгын исәпкә алганда, безнеңчә, әлеге легенда көньяктан башлангыч ала торган «Чура батыр» дастанының үзенчәлекле татар варианты тууына күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган булса кирәк, дип уйларга нигез бар, әмма ул чакта әле эпик каһарман гомумиләштерүче Чура (батыр, батыр сугышчы) дигән гомумтөркки исем белән аталмаган булуга охшый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Чура батыр» дастанының татар варианты нугай-казахлар арасында формалашкан тарихи-героик сюжетның, ике регионга караучы антротопонимнар һәм баскынчы яуларга каршы сугышлар тәңгәллегеннән чыгып, Казан ханлыгының җимерелү чорына яраклаштырылуы җирлегендә барлыкка килгән. Анда мәркәзебез Казанны һәм дәүләтчелегебезне яклап көрәшкән ил батырларының җыелма образы, ягъни масса күләмендә күрсәтелгән халык батырлыгының үзәк каһарманга бәйләп гомумиләштерелгән героик тибы гәүдәләндерелгән. Шул ук вакытта символик мәгънәгә ия булган Чура батыр образына шәһәрне саклаганда шәһит һәм корбан булган бабаларыбыз фаҗигасенә мөнәсәбәтле трагик мәгънә дә салынган. Халыкның тарихи хәтере һәм сәнгати уйланмага төрелгән иҗтимагый-эстетик бәяләмәсе буларак сакланган бу эпос-дастан безне, узганнардан гыйбрәт һәм сабак алып, халкыбызны милләт буларак саклап калу һәм яшәтү идеясенә каһарманнарча хезмәт итәргә чакыра.

Татар дөньясы

ГАРМУНЧЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарларда элек-электән гармунсыз авыл булмаган. Яшьләрнең аулак өйләре, кич утырулары берсе дә уен-җырсыз, гармунсыз үтмәгән.

Яңа Малыклы районы Әбдери авылы халкы элеккедән килгән күркәм традицияләрне бүген дә кадерләп саклый. Алар шушы көннәрдә

генә гармунда уйнау фестиваль-конкурсы үткәрде.

Әлеге чара нәсел җепләре Әбдеригә барып тоташкан данлыклы шәхес – Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстанның халык артисты, виртуоз баянчы **Рөстәм Вәлиевнең** якты истәлегенә багышланган иде.

Бәйрәмгә Ульяновск өлкәсенең төрле районнарыннан дәрәҗәле кунаклар, тирә-юньдәге авыллардан милләттәшләребез, мәрхүмнең туганнары һәм дуслары килде.

Күркәм чараны оештыручы – Әбдери авылы җирле үзидарәсе җитәкчесе Эмиль Назыйф улы Шәкүров халыкны бәйрәм белән котлады. Фестивальдә катнашучылар моңга сусаган тамашачыны үз талантлары һәм иҗади әзерлекләре белән гаҗәпләндерделәр. Шулай ук кул осталарының иҗат җимешләре күргәзмәсе, «җанлы тарих музее» һәркемнең игътибарын җәлеп итте. Монда музыка уен кораллары, күп төрле сувенирлар һәм кул эшләрен күрергә мөмкин иде.

Конкурста 8 яшьлек балалар да, 76 яшьлек абзыйлар да катнашты. Иң яшь катнашучылар – Димитровград шәһәренең Габдулла Тукай исемендәге 22 нче мәктәбе укучылары Кәрим һәм Әмир Мөхетдиновлар «Гармун һәм җыр» номинациясендә чыгыш ясады. Талантлы балалар өчен җанатарлар төркеме булып гаиләнең төрле буын вәкилләре килгән иде. Хәтта 90 яшьлек әбиләре дә оныкчыкларына сокланып һәм алар өчен борчылып утырды.

Гармун бәйрәме халык иҗаты һәм милли мәдәниятебез белән танышу мөмкинлеге бирде һәм тагын бер матур традициягә әверелде.

Мәрьям ХӘЙБУЛЛОВА.

«Өмет» газетасы.

«АГЫЙДЕЛ»

«Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты Рәзилә ГАЛИЕВАга шушы көннәрдә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелде. Апрель аенда ул шәхси концертын да куйган иде. Рәзилә белән аның иҗаты һәм шәхси тормышы, сәнгатебез хакында әңгәмә кордык.

– Рәзилә, сине аз сүзле, корырак холыклы, диләр, хакмы?

– Кешегә ярый, ялагайлана белмим, менә анысы хак. Төче теләнеп сөйләшү юк, һәрчак «әйе» яисә «юк» дип өзәм. Бәлки, бу этисез үсү галәмәтедер. Минем туган сәгатем белән этинең үлгән сәгате бер. Әни бәбиләп ятканда, аның янына килергә чыккан эти авариягә очрый. Әтине Минзәлә хастаханәсенә китергәннәр, шул сәгатьтә мин туганмын. Үги эти белән үстем, әни гел эштә булды. Миңа яшь ярым вакытта Минзәләнең Калморза авылыннан Актанышка күчеп килгәнбез. Бу авырлыклар мине чыныктырган, күрәсең. Әмма мин хыялый да. Шигырьләр укырга яратам, музыка тыңлыйм. Урманга чыксам, рәхәтләнеп җырлап җибәрәм. Тискәрелегем бар, бар анысы... Кеше әйткәли, Рәзилә, алай эшләмә, ди; ә мин гел үземчә эшлим! Соңыннан үкенгән чаклар да була, бигрәк тә соңгы елларда әнинең сүзенә колак салырга тырышам.

– Җырчы булу хыялың балачактан ук киләме, үскәч туган теләк идеме?

– Бәләкәйдән үк мин Венера Ганиеваның «Шайтан таягы» җырын ярата идем. «Алло, алло, кем кирәк? Ничек инде мин кирәк?» Тузан суырткычның озын шнурын микрофон итеп тотып, диван өстенә менеп басам, водолазка киям – аның муенын башта калдырып, кофтаны артка җибәрәм, анысы, имеш, озын чәч, каршымда түгәрәк зур көзге, шуңа карап, хисләнә-хисләнә шуны җырлый идем.

Укый башлагач, сыйныф җитәкчесе Роза Сергеева мәктәпнең «Тургай», «Таң йолдызы» бәйгеләренә этеп-төртеп чыгара иде. Мин, чыкмыйм, куркам, димен, ул ирексезләп чыгарып җибәрә дә, урын ала идем.

Минем әни бик оста җырлый, концертымда да бергә җырладык. Аның да минеке кебек яңгыравык, чиста тавыш. Әтием бик оста биегән. Авыл малае, брейкданс элементлары белән бии торган булган.

– Сине «Фируми» ансамбленә дә төрткәләп керткәннәр, диләр. Шундый кешеләр булмаса, бәлки, сәхнәгә килми дә калыр идең?

– Бәлки. Ә укытучы һөнәрен сайлаган булыр идем. Композитор Инсаф абый Хәбибуллин җыеп, «Фируми» ансамблен күтәрмәсә, 10 класста укыганда район башлыгы Энгель Фәттахов мине сольный чыгыш белән чыксын, димәсә... Әнә шул вакытта сәхнәне «минеке» дип аңлау килде.

– Сезнең «Фируми» халык вокаль ансамбле исемен алган, вакытында гөрләп эшләгән төркем иде.

– Бу төркем Фирүзә, Рузилә, Миләүшә исемнәреннән алынган, ансамбль шулар белән оешкан. Мәктәпне тәмамлагач, кызлар китә, состав алышына торган. Төркемнең иң көчле чоры Миләүшә Әхмәдуллина, мин, Алсу Нургалиева җырлаган чор. Инсаф абый җыр язамы – шундук безгә куя, 3 тавышка. Йодрыкка төйнәлгән кебек идек. Безне исемләп белмиләр дә, «Фируми» кызлары дип кенә йөртәләр иде. Кичләрен дә бергә, мәктәптә дә бергә. Ул вакытлардагы дуслык, җылылык бүген дә дәвам итә. Үземнең быелгы шушы концертымны куяр алдыннан Алсу (2007 елда фаҗигале төстә һәлак булды – **авт.**) төшемә керде. Миңа кызыл алма суза, концертыңа килә, ди...

Җыр буенча укырга керәм, дигән теләк «Фируми»да чакта башланды. Әни каршы килмәде. Мәдәният институтын сайладым. Беренче имтиханга «Вальс турында вальс» җырын әзерләдем, Сара Садыйкова көе, катлаулы әсәр. 1 турны үттем. Икенче имтиханда сольфеджиодан теория – анысы «4» булды. Бюджет урыннары өчәү генә иде, ә керергә имтихан бирүчеләр бихисап. Деканаттагы бер кыз миңа: «Сез үтмәдегез», – диде. Елыйм. Түләүлегә керергә мөмкинлек юк – елына 50 мең сум. Әнигә, әйдә документларны алыйк, дим. Китәргә торганда Венера Ганиева очрады. Кайтып китәргә җыенуымны белгәч, кире документларны тапшырырга төшереп җибәрде... Холкымның тагын бер ягы – дуамаллык.

– Шулай да институтның халык җыры бүлегендә бушлай уку бәхете эләккән бит.

– Әле Венера Ганиева классында уку бәхете дә эләкте. Ул гел, син минем алмашчым, дия иде. Әмма 2 курста ул мине Руслан Дәминовка, аннары Ирина Горбуновага күчерде. Ул – опера-балет театрында меццо-сопрано тавышлы бик көчле җырчы. Минем тавыш – чиста колоратуралы сопрано, иң югары тавыш. Горбунова миңа түбән ноталар бирә – тавыш бозыла, җырлап булмый. Елап кайтам. Бервакыт тавыш бетте. Шуннан Венера апа үзенең укытучысы Клавдия Щербининага күчерде. Таякка таянып йөри торган, 70 яшьнең арьягына чыккан ап-ак чәчле әби – менә ул миңа базаны бирде! Түбән ноталарга бара, ләкин кинәт түгел. Ә түбәннән соң югарыга менү тагын да рәхәт, диапазон тагын да киңәя.

3 курска күчкәч, 2003 елда Актаныштагы «Фируми» төркеменә халык ансамбле исемен бирделәр. Район мәдәният йорты җитәкчесе Азат абый Нургалиев безне чакырырга Казанга килде. Мин ике ут арасында калдым, кайта алмадым. Аннан соң В.Ганиева белән ике арада аңлашылмаучанлык чыкты, аңа минем хакта гайбәт сөйләгәннәр. Мин түзмәдем, укуны ташладым. Иң зур ялгышым – әнигә 3 ай буе шылтыратмадым, хәбәргә чыкмадым. Бөтен кеше белән элемтәне өздем. Маршрут автобусында билет сатучы булып эшкә урнаштым. Бик кискен сынау чоры булды ул. Казанны күрәсем килми башлап, өйгә кайттым.

– Ә Галимҗан Ибраһимовча әйтсәк, төптән, түбәннән күтәрелергә көчең дә, сәләтең дә җиткән.

– Җиңел булды, димәс идем. Тавыш Ходайдан бирелгән ул, ләкин аны камилләштермичә булмый. Җыр сайлаулар буенча да аңлашылмас этаплар үтелде. Район мәдәният сараена эшкә кердем, соңрак Алабуга мәдәният һәм сәнгать училищесының театрлаштырылган тамашалар куелышы бүлеген тәмамладым. Конкурсларда катнаша башладым. Илһам Шакиров конкурсында катнаштым да, беренче этаптан да үтә алмыйча төшеп калдым. Аны соңрак «Татар моңы»на әйләндерделәр. Шунда 8 нче тапкыр катнашуымда гына лауреат исеме алдым. Чыныгу, мөгаен, шулай үтелгәндер. Конкурсларда йөргәндә, күп кешеләр белән танышасың, аларның распевкаларын тыңлыйсың, аралашасың. Шулай башкалардан да нидер алып, үзеңнеке белән кушасың.

Репертуарны киңәйтү буенча эшләүләр... Шырдый-бырдый гына җыр аласы килми, катлаулырак булсын, дип сайланулар... «Былбыл» җырын мин 2011 елны өйрәнә башлаган идем, өч ел элек кенә чыгардым. Минем кумирым – Казахстан җырчысы Бибигөл Төләгәнова. Аның бөтен җырын тыңлыйм, манераларын алырга тырышам. Шул «Былбыл»ны да болай да сузып карыйм, тегеләй дә. Актаныш сәнгать мәктәбенең вокал укытучысы Джон Мусин янына, Инсаф абый Хәбибуллинга барам, җырлап күрсәтәм. Алар куәтләгәч, тагын да дәртләнеп эшлим. Инсаф абый, гомумән, бик зур терәгем. Җырлар сайлаганда, репертуар төзегәндә иң беренче аңа йөгерәм. Мактамый, әйтеп куя, шул вакытны электереп калсаң-каласың, калмасаң – юк... Хәзер менә тагын бер әсәр әзерлим. Анысында – урман тавышы, тын белән, сулыш алу белән башлана. Шуны сүзгә салырга иде. Көе – кошлар сайравы, җил тавышыннан импровизация. Эстрада исә минем өчен түгел, мәҗлесләрдә җырларга гына яраклы кебек. Сәхнәдә академик вокал белән халык җырларын башкарырга яратам. Минем өчен катлаулырак, ят, минеке генә булган әсәрләр кирәк. Минем генә фишка булсын ул. Ка-

САНДУГАЧЫ

батлануларны аны бөтен кеше дә булдыра.

– Эстрадага исем китми, дисең. Ләкин телевизордан балкучы, зур сәхнәләрдә тамашачы җыючы, популярлыгы белән муллыкта яшәүче җырчыларны күреп, «Ник мин дә шулар арасында түгел? Мин дә булдыра алам бит!» – дип уйлаганың булгандыр бит?

– Эстрадага чыгу өчен мөмкинлекләр булды. 2003 ел - «Барс Медиа»ның иң көчле чагы. «Йолдызлар фабрикасы»н чыгарган вакыт. Минем студент чак, үзебезнең уку йортының вәкиле булып,ниндидер чарада җырладым да, яныма Фәрит Таишев килде. Тавышыгызны ошаттым, үзенчәлекле тавыш, әйдәгез контракт төзибез, ди. Ләкин эстрадада пычраклык күп, гайрәтем чикте.

Джон Мусин мине хәзер дә: «Син бит Зур театрда җырлый торган кеше, үзең театрал, сирәк колоратуралы сопрано тавышың, син шунда примадонна булып йөри торган кеше»,– дип сүгә, ләкин мин аны күз алдына китерә алмыйм. Югыйсә, ансамбль белән читләргә чыгабыз, сәхнә туп-тулы, алкышлар, чәчәкләргә күмәләр. Шуларны тою-ишетү рәхәт, күңелгә бал да май булып ята. Ләкин үземне зур сәхнәдә күрмим.

– Күңел яраларыңны кузгатырга теләмәсәм дә, гаиләң турында да сорамыйча булмый...

– Ирем Нияз – Актанышның Татар Суыксуы авылы егете, медицина университетын тәмамлаган, икенче белеме – физкультура академиясендә адаптив физкультура буенча. Чаллыда балалар һәм яшүсмерләр өчен «Солнечный» реабилитация үзәгендә инвалид балалар белән эшли иде – ДЦПлы 4 баланы аякка бастырды. Аларны дельфиннар белән йөздерә, атларда йөртә, массаж ясый, әллә нинди тренажерларда тарттырып, җанын биреп эшли иде. Күңеленә һәр нәрсәне бик якын ала, борчыла торган кеше, эшен ташлады ахырда. Кайтып, Суыксу мәктәбенә физкультура укытырга керде.

Бик көчле рухлы кеше иде. Берәр вакыт сүгенгәнә булса! Матур итеп сөйләшә, аның янәшәсендә гел кеше була, кинәшкә киләләр иде. Гастрольләргә чыгып китәбез, мәҗлесләргә-туйларга йөрибез бит инде – миңа ник бер кыек сүз әйтсә! Балаларны алып кала иде. Бергә берәр җиргә барсак: «Минем хатынны җырлат әле», – дип, тамаданы аптыратып бетерә иде. Яратмаса, ул минем эшемне хөрмәт итмәс иде.

– Ничек танышкан идегез?

– 2006 елның 29 декабрендә Ниязның туган апасы безне авылларына Яңа ел бәйрәменә җырларга чакырды. Менә шушы машина кайтарып куяр, дип безне бер машинага утыртты. Алда ике егет, артта без – ике кыз. Таныштык. Юлда кемнең туган көне кайчан дигән сүз китте. Бер машинада гел дүртебез дә майныкылар булып чыкты. Минеке – 14 май. Нияз моны ишеткәч: «Ничек инде 14 май? Булмаганны! Минеке дә 14 май бит», – ди. Рузилнеке 16 май, Ленараныкы 19 май булып чыкты. Бик кызык тоелды бу безнең өчен. Шуннан аралаша башладык.

Безнең телефон мәхәббәте булды. Әле кәрәзле телефоннар чыга гына башлаган вакыт. Бездә ул юк. Төннәр буе стационар телефон аша сөйләшәбез. Әни йокысыннан торып чыга, куй инде, балакаем, телефонны, мине дә йоклатмыйсың, үзең дә йокламыйсың, ди, туйда да шуны искә төшерде.

Өйләнешкәч, кайнана-кайната янында авылда 10 ел яшәдек. Дәрәҗәле кешеләр. Күп итеп мал асрыйлар, 7 шәр сыер сава идек. Ир – төпчек бала, әти-әни яныннан китмим, диде. Мин Актаныш мәдәният йортына эшкә чыктым, көн дә иртән машина белән эшкә йөрим. Балалар авыл мәктәбенә укырга керде. Соңыннан миңа Актанышта фатир бирделәр. Ниязны көчкә күндереп алып килдем. Авылда төпләнәсе килә иде. «Мин ничек ике бүлмәле фатирда яши алыйм?» – ди торган иде. Өй салырга планнар да корган идек.

– Узган ел Ниязыңның фаҗигале төстә гомере өзелде...

– Һаман да ышанасы килми. Туган көн җиткәч, быелтыр аңа 40 яшь тулды, миңа 37, зурламый гына утырабыз, дидек. Бәйрәм үтте. Кайткач, никтер миннән сорады: «Мин булмасам, нишләр идең икән?» – ди. «Ник алай дип сорыйсың?» – дим. Бераздан өстәде: «Миңа күп калмады. Минсез рәхәт яшәрсең микән?» – ди. «Ни сөйлисең? Син ятимлекнең нәрсә икәнен белмисең, мин беләм»,– дидем. Үги ата белән үскән бала бит инде мин, кыйналуларны да кичергән. «Шушы балаларны кеше итмичә ничек китә аласың?» – дип, елый-елый ачуландым. Дәшмәде.

23 июльдә Тозлы күлгә ялга киттек. «Күрсәтеп алып кайтыйм әле», – диде. Без арендага алган йортта тагын бер гаилә бар иде. Кызы белән килгән бер хатын. «Бир, багыйм әле», – дип, минем кулны алды бу. «Юк, андый нәрсәгә ышанмыйм», – дип тартып алдым. Бер арада иремнекен караган бу. «Синең 10 көн гомерең калган!» – дигән бу хатын аңа. Нияз коелып төшкән. Шуннан соң ул сулды. Теге хатынны ачуландым, нигә бактың, ир кеше бит ул, нигә андый сүзләр әйттең, дидем. Ә ул: «Син кулыңны тартып алдың бит, ирең дә каршы килә ала иде. Мин мәҗбүри бакмадым», – дип акланды...

Ял итеп кайттык, Нияз һаман уйда. Беркөнне дус малайлары кунакка килдебез, дигәннәр. Сарык суйды, хашлама пешерде. 8 август көнне шулар белән су буена ял итәргә төшеп киттеләр. Кич белән балаларны алып, мин дә килдем. Бәләкәй кызны кулыннан да төшерми. Без кайтырга җыендык, бәләкәй кызыбыз әтисенең муеныннан җибәрми генә: «Әтием, «пока» әйтмим, әтием, яратам!» – дип кычкырып елый. Көчкә алып киттем. Юл буе, төн буе елады, температурасы күтәрелде. Иртән 8 тулганда Нияз, тиздән кайтам, дип шылтыратты. Төпчегебез Язилә һаман елый, әти, кааайт, дип өзелә. Алар гел бергә, бик якын иделәр, әтисе тезеннән дә төшерми иде. Көндез 11 тулганда кичтән төшкән фотоларны җибәрде. Ярты сәгатьтән чыгам кайтырга, диде дә, югалды.

...Төне буе эзләдек, икенче көнне водолазлар чакырткач кына табылды. Су өстендә торган мунчаның кырыеннан гына алдык Ниязны... Бөтен авыл елады. Бөтен группадашлары кайткан иде, дуслары килде. Балалар – өч кызыбыз Зәлия, Сәйдә, Язилә бик авыр кичерде. Криминал булды инде ул, чын криминал. Артыгын сөйләмим.

– Бу олы кайгыны сынмый-сыгылмыйча, көчле хатын булып кичерә алдың кебек.

– Мин көчле түгел. Ләкин әчем тулы кара кан булса да, мин аны кешегә чыгармыйм. Шулай өйрәттеләр: кеше күрмәсен, сиздермәгез, һәрчак елмай! Эштә йөрисең дә, өйгә кайтып, дүрт стена арасында бикләнгәч, газап башлана. Әле һаман да мин Ниязга ватсаптан хат язам, җавап кына юк... Әле бүген дә мин аны һаман көтәм. Һаман кайтып керер кебек...

– Иреңә үлеменә ел тулмастан зур концерт ясап чыкты, дигән сүзне ишетүдән курыкмадыңмы?

– Юк, уйламадым да. Чөнки үземне нәрсәдер белән мәшгуль итәргә кирәк иде, мин шушы концертны уйлап йөрдем. Ананан, Нияз гел «Исем алу өчен эшләргә кирәк», дип әйтә килде... Иртәгә концерт дигән көнне Нияз төшемә керде. Нык зур букет күтәргән. Куе кызыл төстәге эре-эре розалар...

– Әти-әниләре белән аралашасызмы?

– Аралашабыз. Балалар өчен алар үлеп тора. Концертыма да бөтенесе җыелып килде. Зур бер төркем булып чыктылар, чәчәкләр белән. Син безнең сеңелкәш кебек, диләр туганнары. Алар миңа бик якын. Бик ярдәм итеп торалар, балаларга планшетка кадәр алып бирделәр.

– Инде 2016 елдан бирле син «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамблендә җырлыйсың. Синең өчен «Агыйдел» ул – яулап алган биек үрме, алга баруда чираттагы баскычмы?

– Ул – минем яшәү чыганагым. Әти-әнием, туганнарым, балаларымнан тыш, кайгымны уртаклашучы да, шатлыгымны бүлешүче дә коллектив бу. Ниязны җирләргә дә ансамбль тулы килеш килгән иде. Үзара без җылы мөнәсәбәттә, гел бергә. Без монда бергә яшибез дисәң дә була, гастрольләргә чыгып киткәч, 10-20 көн бергә бит. Туганлашып беттек, дөресен әйткәндә.

– «Агыйдел» ансамбле эшчәнлегенә татар мәдәниятен күтәрүче буларак нинди бәя бирер идең?

– «Агыйдел» 2012 елда дәүләт ансамбле статусын алды, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты. Ансамбль буларак, без, чынлап та, зур эш башкарабыз. Бик зур хезмәт. Биючеләр көн саен 8 әр сәгать бию өйрәнә. Без яңа җырлар эзлибез. Россияне иңләп-буйлап гастрольдә йөргәндә, шул төбәкләрнең фольклорыннан нидер алабыз. Классика – Сәйдәш, Яхиннарны онытмыйбыз. Чит төбәкләргә чыкканда, зал шыгрым тула. Сусаган халык. Татарстанда ул кадәр булмаса да, башка өлкәләрдә кабат-кабат чакырып, аягүрә басып кул чабалар. Шул вакытта үзеңнең бик тә кирәклегеңне тоясың. Күңелдә шундый да зур горурлык туа!

Гөлназ ХӨҖҖӘТОВА.
Актаныш.

Әлмира абыстайны сагынабыз

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1995 елдан бирле Татарстан хатын-кызларының «Мөслимә» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, күренекле журналист Әлмира Лотфулла кызы Әдиятуллинага быел 85 яшь тулган булыр иде. Без аның белән 22 ел бергә иңгә-иң торып эшләдек. Әлмира Лотфулла кызының булдыклылыгына, оештыру сәләтенә һәрвакыт хәйран кала идем.

Әлмира Әдиятуллина 1995 елдан бирле Татарстан хатын-кызларының «Мөслимә» оешмасын җитәкләде. Алар беренче көннәреннән үк ислам диненә каршы килә торган төрле хәрам хәлләргә, вакыйгаларга карата мөнәсәбәтләрен ачыктан-ачык белдереп килде. Юл буйларына, урамнарга эленгән әхлакка ятышсыз рекламаларны, Кремль янының сыраханәне алдырумы, укытучыларның укучылар, аеруча югары сыйныф егет-кызлары алдында тыйнак киенергә тиешлеге мәсьәләсен күтәрүме – Әлмира ханым берсенә дә битараф булмады. Шөкер, тырышлыклары да бушка китмәде. Ә инде мөселман хатын-кызларының паспортка кую өчен фотога яулык бәйләп төшү хокукын яклап, «Мөслимә»ләр Мәскәүгә кадәр барып җитте, аларга 8 мәхкәмәдә катнашырга, үзләренең хаклы икәнен исбатларга туры килде. Алар Казанның Меңьеллык мәйданында «Сотворение мира» фестивален уздырмас өчен дә берничә ел көрәште.

Ә.Әдиятуллина Коръән аятьләрен уку буенча «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесен оештырып килде. Ислам динебезне куәтләүче, иманлы, әдәп-әхлаклы, игелекле, җәмгыятебезгә файда китерә торган тәрбияле балаларыбыз үссен дип тырышты.

Казаннан, Татарстан район-авылларыннан, Чуаштан, Мордовия республикаларыннан, Ульяновск, Саратов, Ижевск, Самара шәһәрләреннән 4 яшьтән 18 яшькәчә 500 ләп бала бәйгегә килүе хәтеремдә калды. Ул балаларны: «Хуш килә сез, оланнар, сезгә уңышлар!» – диеп, сөенеп каршы ала иде. Аңлашыла ки, «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесен оештыру гаять чыгымлы чара булды.

Мин ул елларда «Тынычлык» мәчетендә балалар укыттым. Әлхәмдүлилләһ, шәкертләрем белән бу бәйгеләрдә катнашып, аларны ел саен бүләкләр белән сөендердем. Әлмира абыстай да: «Сәдака акчаларыны җыеп куй, балаларга бүләк алырбыз», – дип искәртә торган иде. Һәрбер балага төрле бүләкләр, призлы урыннар бирелде. Берсе дә бүләксез калмады. Балтач районыннан мөгаллимә Ландыш Рафис кызы бәйгегә алып килгән балаларны Аллаһ ризалыгы өчен акчалата бүләкләдем. Әлмира абыстайның үзенең дә, арба тартып, конкурста катнашучы балаларга тапшырылачак бүләкләрне хәлләрәк кешеләрдән җыеп йөргәне хәтерләрдә озак сакланыр әле.

Ә.Әдиятуллина 20 ел дәвамында үз акчасына һәм хәйриячеләр ярдәме белән бик әһәмиятле «Мөслимә» газетасын чыгарып килде. Газетаны укып баручылар арасында динебезгә килүчеләр дә булгандыр. Әлмира абыстай үзе дә өч тапкыр хаҗ кылып кайтырга өлгерде.

Әлмира абыстай соңгы елларда «Ярдәм» мәчетендә хезмәт куйды. Журналист һәм җәмәгать эшлеклесенең биредә эшли башлагач яңа сулышы ачылып киткәндәй булды.

Бердәнбер казыя Мөхлисә Буби исемендәге иң затлы «Сөембикә» беләзегенең дә беренчеләрдән булып Әлмира Лотфулла кызына тапшырылуы аның алып барган тынгысыз эшчәнлеген хаклап бәяләү булды.

Кызганыч ки, гомерләр кыска, Ә.Әдиятуллинаның да бакыйлыкка күчкәненә ике ел була. Ул гомеренең соңгы көненә кадәр үзенең тоткан мәсләгенә тугры калды. Аның миндә онытылмас бүләге кадерле истәлек булып саклана. «Ихлас күңелле, олы җанлы дускаем Сәлимәгә булсын бүләгем – китабым! Әлмира Әдиятуллина, 10.06.2016 ел», – дигән сүзләр язылган.

Сәлимә абыстай ХӨСӘЕНОВА.
Казан шәһәре.

Каһарман

(Ахыры. Башы 23 нче санда).


114
03908
Все графы заполнять полностью
550

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество РАХМАТУЛИН Миниар Баталович
2. Звание Подполковник 3. Должность, часть Командир 512 стрелкового полка 146 стрелковой дивизии
Представляется к Ордену "КУТУЗОВА 3-й СТЕПЕНИ"
4. Год рождения 1898 5. Национальность Татарин 6. Партийность ЧВКП(б) с 1920 г.
7. Участие в гражданской войне и в последующих боевых действиях по защите СССР (где, когда)
В гражданской войне с 1919 по 1921 г. В отечеств. войне с 23.3.42 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Ранен и контужен не был
9. С какого времени в Красной Армии С 1919 года 10. Каким РВК призван
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Медаль 20 лет РККА
12. 1

ДЛЯ ПОДШИВКИ

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

т.РАХМАТУЛИН очень старый опытный командир. В дивизии с начала ее организации и все время в должности командира 512 СП. Его полк был лучшим при действиях в районе [illegible]. За все время нахождения в обороне, не пропустил через свою оборону ни одного немца. Все попытки противника всегда своевременно обнаруживались и метким огнем обороны немедленно отбивались – так было в августе, сентябре и октябре 1942 года.

Оборона полка комиссией Зап. фронта признана лучшей в [illegible] армии, также отмечала комиссия ВПУ под руководством т.КУЗОВКОВА в ноябре 1942 года.

т.РАХМАТУЛИН лично сам указывал место посадки каждого ДЗОТа. На обороне бывает почти ежедневно. Оборону полка знает хорошо.

За хорошо организованную оборону полка и умелое руководство во время активных действий обороны полка – достоин Правительственной награды Орденом "КУТУЗОВА 3-й СТЕПЕНИ".

КОМАНДИР 146 СТРЕЛКОВОЙ ДИВИЗИИ
ПОЛКОВНИК /ДУЛОВ/
Командир (начальник) Военный комиссар
(звание) (звание)
13 февраля 1943 г.

Тәкъдим 1 нче гвардия бомбага тоту авиациясе дивизиясе командиры гвардия полковнигы Федор Добыш һәм 1 нче гвардия бомбага тоту авиациясе корпусы командиры гвардия полковнигы Иван Полбин (25 октябрьдән – генерал-майор) тарафыннан да яклау таба. 25 август көнне баш штурманы милләттәшебез – полковник Мөхәррәм Галимов булган 5 нче һава армиясе гаскәрләре буенча үз хәрбиләрен орден-медальләр белән бүләкләү турында яшерен Боерык чыга. Боерыкны имзалаучылар – армия командующие авиация генерал-лейтенанты Сергей Горюнов һәм штаб башлыгы авиация генерал-майоры Николай Селезнев. 1945 елның 29 гыйнварында полкның яңа командиры гвардия подполковнигы Николай Зайцев (17 июньнән – Советлар Союзы Герое) штаб башлыгы Шамил Рәхмәтуллинны I дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итеп тутырылган бүләкләү документына кул куя. Тәкъдим 1 нче гвардия бомбага тоту авиациясе дивизиясе командиры Федор Добыш, 6 нчы бомбага тоту авиациясе корпусы командиры авиация генерал-майоры Феофан Качев һәм 1 нче Украина фронты составындагы 2 нче һава армиясе командующие авиация генерал-полковнигы Степан Красовский тарафыннан да яклана. 1 апрель көнне үз хәрбиләрен орденнар белән бүләкләү турында армия командующие Красовский белән аның штаб башлыгы авиация генерал-майоры Александр Пронин тарафыннан имзаланган яшерен Боерык чыга. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүче 9 яугирнең берсе – 80 нче гвардия бомбага тоту авиациясе полкының штаб башлыгы гвардия майоры **Шамил Сәлим улы Рәхмәтуллин,** сугыштан соң – полковник, 1951 елда – Кызыл Йолдыз һәм 1956 елда Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнә.

1912 елда Ульян каласында туган, СССР Хәрби-һава көчләренең авиатехника төзелеш-тәҗрибә идарәсе башлыгы урынбасары, илнең Хәрби-диңгез флоты Хәрби-һава көчләренең инженер-техник хезмәте генерал-майоры **Шамил Котдус улы Рәхмәтуллин** турында Татар энциклопедиясендә мәгълүмат эзләү урынсыз гамәл. Ни аяныч, башыннан ахырынача Бөек Ватан сугышында катнашкан, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм күп санлы медальләр кавалеры, генерал-майор Шамил Котдус улы милләт казанышы саналырга тиешле хезмәттә күрсәтелергә лаек табылмаган. 1943 елның 11 июнендә Кызыл Байраклы Балтыйк флоты Хәрби-һава көчләре составындагы 8 нче авиабригаданың 73 нче авиаполкы командиры подполковник Курочкин, инженер-капитан Рәхмәтуллинны II дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итеп, бүләкләү документын имзалый. Ел дәвамында полкта 80 хәрби, 880 өйрәнү очышы ясалган, һәм шәхсән өлкән инженер Рәхмәтуллинның самолетларны техник һәм материаль яктан өзлексез тәэмин итеп торуы нәтиҗәсендә өзеклекләргә юл куелмаган. Ул үзен аеруча Ленинград блокадасын өзү өчен алып барылган сугышлар барышында уңай яктан таныта. Тәкъдим бригада командиры полковник Суханов тарафыннан да каршылыкка очрамый. Ниһаять, үз хәрбиләрен I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләү турында 4 августта Кызыл Байраклы Балтыйк флотының Хәрби-һава көчләре командующие авиация генерал-лейтенанты Михаил Самохин белән штаб башлыгы полковник Александр Шугинин кул куйган Боерык чыга. Тик анда II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүче инженер-капитан Рәхмәтуллин полкының 8 нче авиадивизия составында дип күрсәтелүе бераз сагайта төшә. Гәрчә монда төгәлсезлек яисә хата эзләү урынсыз. Документларда кыскартып язылса да, полкның һәм бригаданың тулы исемнәре – 73 нче бомбага тоту авиация полкы һәм 8 нче бомбага тоту авиация бригадасы. 1943 елның 12 июлендә бригадага Яңа Ладога аэродромында урнашкан 51 нче мина-торпеда полкы кушыла, һәм ул 8 нче мина-торпеда авиация дивизиясе итеп үзгәртелә. Милләттәшебез исә 1945 елның 22 июнендә «Алманияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгәндә инженер-майор званиесендә була. Каһарман милләттәшебез турында тулы мәгълүмат армиянең Үзәк архивында (Ф. 2637, оп. 1, 33 ед. хр., 1933-1981) саклана.

1944 елның 2 июлендә 362 нче укчы дивизия командиры генерал-майор Михаил Еншинның саф буенча урынбасары, татар полковнигы **Миңнияр Баттал улы Рәхмәтуллинның** гомерен алман снайперы өзә. Белорус республикасының Минск өлкәсенә кергән Червень каласындагы скверда җирләнгән милләт баласы – Башкортстаннан, Авыргазы районының Семенкино исемле

Рәхмәтуллиннар


НАГРАДНОЙ ЛИСТ.

1. Фамилия, Имя и Отчество: РАХМАТУЛЛИН Шамиль Салимович.

2. Звание: Гвардии майор. 3. Должность, часть: Начальник штаба 80 Гвардейского Бомбардировочного Авиационного полка.

Представляется к Ордену "КРАСНАЯ ЗВЕЗДА".

4. Год рождения: 1910 г. 5. Национальн. Татарин. 6. Партийн. чл. ВКП/б/-4[illegible]

7. Участие в Гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (когда где): Находится на фронтах Отечественной войны с 22.6.41 года по настоящее время.

8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне. Не имеет.

9. С какого времени в Красной Армии: с 1936 г. 10. Каким РВК призван

Кадр Красной Армии.

11. Чем ранее награжден (за какие отличия). Не имеет.

12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи: [redacted]

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

За время участия в отечественной войне на Зап. фронте совершил 5 успешных боевых вылетов. В настоящее время работая начальником штаба полка с работой справляется хорошо. До этого работал зам. нач. штаба полка по опер. развед. части. Все свое знание и опыт передает подчиненным, много, упорно и усидчиво работает над оформлением боевых документов, ведение карт, учета и отчетности по учебной и боевой работе полка. Своевременно и правильно доводит и ставит боевую задачу летному составу. Тактически грамотный.

В период нахождения полка на ВОЛХОВСКОМ фронте в отсутствии 50% технического состава и 50% мл. авиаспециалистов сумел организовать и обеспечить бесперебойную боевую работу, в полку не было срывов выполнения задания, не было невыходов, а интенсивность была по 2 вылета в день. При перебазировании с ВОЛХОВСКОГО на Северо-Западный фронт сумел организовать перебазирование в течении одних суток всего личного состава и имущества, на следующий день полк приступил к боевым действиям.

В период боевых действий на ВОРОНЕЖСКОМ фронте обеспечил выполнение и проведение в жизнь всех решений командира. Не было ни одного случая по вине штаба срыва полетов. Боевая задача ставилась экипажам правильно и своевременно.

Как штабной командир усидчив в работе, а в период напряженной работы не считается с [illegible] и трудностями, работает круглыми сутками планированием учебной и боевой работы.

За [illegible] работу по обеспечению б/работы полка в борьбе с фашистскими захватчиками достоин награждения орденом "КРАСНАЯ ЗВЕЗДА".

КОМАНДИР ПОЛКА 80
ГВАРДИИ [illegible] РЫТАЛЬЧ[illegible]

"26" июня 1943

татар авылында туган. 1877 елга 2 мәчете, 2 мәдрәсәсе, 12 кибете булган, якшәмбе көннәрендә базары эшләп торган авылдагы 170 йортта 851 мишәр һәм типтәр яшәве мәгълүм. Әле 1921–1922 елларда ук Көньяк, Төркестан фронтларында сугышкан һәм Бохара республикасының Кызыл Байрак ордене белән бүләкләнгән Миңнияр Рәхмәтуллин 1941 елның декабрендә Мәскәү хәрби округының Казан каласында оешкан 146 нчы укчы дивизия (II формирование) составындагы 608 нче укчы полкның командиры итеп билгеләнә. 1941 елның февраленнән Тула өлкәсенең Венев каласы тирәсенә, Югары Башкомандование Ставкасы резервына чыгарылган генерал-лейтенант Юрий Новосельцев командалык иткән дивизияне тагын бер айдан Көнбатыш фронт составындагы 50 нче армиягә кушалар. Татарстан яугирләре бирегә яуга керә һәм Мосальск каласы тирәсендәге алгы сызыкта сафлары сирәгәеп калган 173 нче укчы дивизияне алыштыра. 11 апрельдә дивизия 1 нче Фомино һәм Зимница авыллары рубежына чыга һәм Варшава шоссесын «өзү» өчен аяусыз сугышлар башлый. Әмма бернечә мәртәбә юлны кисүләренә карамастан, сафларының 75%ын югалткан дивизия яугирләре уңышка ирешә алмый, нәтиҗәдә аларны 58 нче укчы дивизия алыштыра. Май урталарында 50 нче армия составындагы 146 нчы укчы дивизия 49 нчы һәм 59 нчы армияләр кисешкән урында оборонага баса. Подполковник Рәхмәтуллин исә 31 августта күршедәге 512 нче укчы полк командиры итеп билгеләнә һәм Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Дөрес, әүвәл, 146 нчы укчы дивизиянең яңа командиры полковник Дулов милләттәшебезне III дәрәҗә Кутузов орденына тәкъдим итеп, 1943 елның 13 февралендә бүләкләү документын имзалый. Тарихи документта подполковник Миңнияр Рәхмәтуллинның 1нче Фомино авылы тирәсендәге сугышларда үзен тәвәккәл командир булараак танытуы, август-октябрь айларында оборонада торганда, полк яугирләренең бер адым да чигенмәүләре һәм безнең якка «бер генә алман хәрбиен дә» үткәрмәүләре ташка басылган. Ноябрь аенда хәрби-сәяси идарә ясаган нәтиҗә күрсәткәнчә, 512 нче укчы полк 50 нче армиядә иң яхшы полк буларак бәяләнә. Мөгаен, шул сәбәпледер, армиянең хәрби советында Миңнияр Баттал улын күпкә дәрәҗәләрәк Кызыл Байрак ордены белән бүләкләргә карар кылына. Документны имзалаучылар – 50 нче армия командующие генерал-лейтенант Иван Болдин һәм Хәрби совет әгъзасы генерал-майор Леонид Чумаков. 22 февральдә 50 нче армиянең подполковник званиесендәге өч полк командирын орденнар белән бүләкләү турында Көнбатыш фронт командующие генерал-полковник Конев һәм Хәрби совет әгъзасы генерал-лейтенант Булганин имзалаган яшерен Боерык чыга. Фронтның Хәрби советы карары белән 512 нче полк командиры Миңнияр Рәхмәтуллин – Кызыл Байрак, ә Николай Аверихин белән Сергей Никитин II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

Серле бер вәзгыять. 1943 елның 12 мартында Көнбатыш фронтның үз составындагы армияләр яугирләрен бүләкләү турындагы командующий генерал-полковник Василий Соколовский һәм Хәрби совет әгъзасы генерал-лейтенант Николай Булганин имзалаган яшерен Боерык дөнья күрә. Андагы 49 нчы армия буенча бирелгән исемлектә Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнүче ике генә татар полковнигы бар: алар – 146 нчы укчы дивизиянең 512 нче укчы полкы командиры Миңнияр Рәхмәтуллин һәм шул ук Татарстанда оешкан дивизиянең артиллерия башлыгы Шаһи Садыйков. Тик инде бүләкләү исемлегенә кертелгән ике полковникның да фамилиясе шәхсән фронт командующие Соколовский тарафыннан сызып ташланган. Чөнки нәкъ шул чорда аларның икесе дә 50 нче армия буенча хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителеп, Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнә. Шаһи Садыйков Әлки районының Каргалы авылы егете, әле 1941 елның июль аенда ук Ленин орденына тәкъдим ителә, 1943 елның 13 мартында исә Кызыл Байрак ордене белән бүләкләнә, әмма язмыш аямый: 21 мартта һәлак була.

58 нче запастагы һәм 324 нче укчы дивизия составындагы 1059 нчы укчы полклар белән командалык иткән Рәхмәтуллинны 50 нче армиянең Хәрби советы карамагына күчерәләр, ягъни аны югарырак дәрәҗәле яңа вазыйфага билгеләнү көтә. Нәкъ шул мәлне, 1944 елның 20 апрелендә, армия командующие генерал-лейтенант Болдин, полковник Миңнияр Рәхмәтуллинны Александр Невский орденына тәкъдим итеп, бүләкләү документына кул куя. 1943 елның 13 декабреннән алып 1944 елның февраль аена чаклы 50 нче армия һөҗүмгә күчкәч, тәвәккәл, кискен хәлләр туганда югалып калмаучы полковник Рәхмәтуллин үз полкы белән дивизиянең башка частьларына уңышлы хәрәкәт итү мөмкинлеге тудыра. 29 апрельдә 2 нче Белоруссия фронты составындагы 50 нче армия буенча үз яугирләрен орденнар белән бүләкләү турында командующий генерал-лейтенант Иван Болдин белән Хәрби совет әгъзасы генерал-майор Арсений Карамышев (тәгаен ачыкланмаган тагын бер татар генералы) имзалаган яшерен Боерык дөнья күрә. А.Невский ордены белән бердәнбер бүләкләнүче – армия Хәрби советы карамагында торучы 1059 нчы укчы полкның элекке командиры полковник Миңнияр Рәхмәтуллин. 1945 елның июненнән ул – 1941 елның ноябрендә Омск каласындагы пехота училищесы базасында оешкан 362 нче укчы дивизия командирының саф буенча урынбасары. Кызганыч, ул вазыйфада озак хезмәт итәргә туры килми: курку белмәс, үз-үзен аямаучы һәм һөҗүмнәр вакытында гел генә яу кырында алгы сафларда булырга күнеккән полковник Рәхмәтуллин, хатыны Зәйнәпне тол калдырып, фаҗигале төстә һәлак була.

Вафатыннан соң дивизия командиры генерал-майор Михаил Еншин, каһарман милләттәшебезне I дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итеп, 6 июль көнне бүләкләү документына кул куя. Анда милләттәшебезнең 27 июньдә дивизия командирының саф буенча урынбасары итеп билгеләнүе, командование тарафыннан төшерелгән хәрби бурычларны намус белән батырларча үтәве, шул көннән алып 2 июльгә чаклы дивизиянең 300 чакрым юл үтүе һәм аз югалтулар белән Днепр, Десна елгаларын кичүе бәян ителә. 2 июль көнне сугыш вакытында алман снайперы пулясы каһарман яугирнең гомерен өзә. 30 июльдә, үз ризалыкларын белдереп, документны 50 нче армия командующие Иван Болдин белән гвардия генерал-майоры Арсений Карамышев имзалый. 10 августта үз яугирләрен бүләкләү турында 2 нче Белоруссия фронты командующие армия генералы Георгий Захаров, Хәрби совет әгъзасы генерал-лейтенант Никита Субботин һәм штаб башлыгы генерал-лейтенант Александр Боголюбов имзалары төшкән яшерен Боерыктагы I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнүчеләр арасында мәрхүм полковник Миңнияр Рәхмәтуллинның исеме дә бар. Шундый шанлы юл үткән каһарман ир-атны үз авылларында белмәүләре, үзләреннән чыккан күренекле шәхесләр исемлегенә кертмәүләре бик аяныч.

Рәис ЗАРИПОВ.

Татар дөньясы

ДОГА КЫЛЫП, ЯҢГЫР СОРАДЫК

Эссе һава торышы, корылык табигатькә зур зыян сала. Янгын афәтләреннән һәркем куркып тора. Менә шуларны күздә тотып, кайбер авылларда, Аллаһның яңгыр бирүен ялварып, «Күк корбанлыгы» йоласын уздыралар.

Шундый чара Төмән районы Талмы авылы мәчетенең ишек алдында, бөтен авыл халкы катнашында үтте. Ел саен үткәрелеп килгән йоланы авыл активисты Фәрзәнә Буранчина оештырды. Ул социаль челтәрләрдәге авыл төркеменә язып, әлеге эшкә өлеш кертүләрен сораган. Аның тәкъдимен халык хуплап, кемнәр нинди эштә катнаша алулары, хатын-кызлар нинди ризыклар пешереп әзерләүләре турында алдан килешкәннәр.

Бәйрәм чарасы мәчеттә намаз укудан башланып китте. Аннары кунакларны милли ашлар белән ташып торган табынга чакырып, токмачлы аш белән сыйладылар. Шул ук вакытта Руслан хәзрәт Мәмәтов яңгыр теләп дога кылды, вәгазь сөйләде. Чараны оештыруда ярдәм итүчеләргә рәхмәт белдереп, Талмы авылы халкының активлыгын, бердәмлеген телгә алды, эссе көннәр турындагы хәдисләрне искә төшерде. Өлкән буын кешеләре таралганнан соң, хатын-кызлар, балалар бер-берсен су белән коендырып, шаярып та алдылар.

Көнозын халык сыйлаудан бушамаган Фәрзәнә ападан чара турында сораштык.

– Авылдашлар, читтә яшәүче якташларыбыз ярдәме белән җыелган акчага Шыкча авылыннан тана сатып алдык. Аны Аллаһ Тәгаләнең ризалыгына ирешү ниятеннән, яңгыр бирүен сорап корбан итеп чалдык. 100 кг иттән хатын-кызларыбыз аш пешерделәр. «Күк корбанлыгы» йоласын күпләр суфилык юнәлешенә кертә. Без Аллаһ Тәгаләдән яңгыр бирүен һәм саулык, илебезгә тынычлык сорап 2 рәкәгать намаз укыйбыз. Әүвәлге елларда елга буенда корбан чалып үткәрә идек. Ә быел төбәгебездә гадәттән тыш янгын куркынычы саклану сәбәпле, ачык җирләрдә ут ягулар тыела. Шуңа мәчет ишек алдында өстәлләр әзерләдек, – дип сөйләде.

Розалия Фәтхетдинова әйтүенчә, «Күк корбанлыгы» уздырганнан соң, гадәттә, яңгыр яумыйча калмый икән. Тик бу юлы Талмы өстендә болытлар куерса да, яңгыр авылны әйләнеп үтте.

Рәүфә КАНГАЗИНА.
«Яңарыш» газетасы.

Нурихан ФӘТТАХ

Сөннәткә бирү йоласы

Сөннәткә бирү (сөннәткә утырту яисә бабага бирү) йоласын да үлеп терелү йоласының бер калдыгы дип карарга кирәк.

Сөннәткә бирү йоласы татарларда һәм башка төрки, төрки булмаган халыкларда очрый. Бездә бу йоланы ислам дине белән бергә гарәптән кергән диебрәк аңлаталар. Сөннәткә бирү йоласы гарәпләргә, имеш, борынгы яһүдләрдән күчкән. Борынгы яһүдләр моны, имеш, гигиена таләпләреннән чыгып кулланганнар. Б.э.к. V гасырда яшәгән һәм Мисырны үз күзләре белән күргән Геродот та сөннәтне шулайрак аңлата. «Җенес әгъзаларының тиресен алар чисталык өчен кисеп ташлыйлар», – ди ул борынгы Мисыр кешеләренең әлеге йоласы турында сөйләгәндә. Сөннәткә бирү тазалык, чисталык өчен кирәк дигән аңлатма Геродотның менә шушы сүзләренә нигезләнмәде микән?

Ләкин бу йоланы гигиена таләпләре белән аңлату ышандырмый. Моны шулай ук ислам дине кануннары белән дә аңлатып булмый. Чөнки «бу йолага карата Коръәндә бернинди күрсәтмә юк; ул хәтта телгә дә алынмый. Шуңа күрә сөннәткә бирү йоласының мәгънәсен ислам диненнән дә, борынгы Мисыр һәм шулай ук борынгы яһүд медицинасыннан да түгел, бәлки Яңа Гвинея, Австралия халыкларының үлеп терелү йоласыннан эзләү дөресрәк булачактыр.

«Җир йөзендә борын-борыннан бары тик өч халыкта гына: колхларда, мисырлыларда һәм эфиопларда гына сөннәткә бирү йоласы бар», – дип яза Геродот. Аның әйтүенчә, бу йола шулай ук Финикиядә һәм Палестина сириләрендә дә билгеле. Полинезия утрауларында, Австралиядә, Яңа Гвинеядә һ.б. җирләрдә киң таралган.

Элекке вакытларда татар авылларында әледән-әле баба яисә бабачы йөри иде һәм яше җиткән ир балаларны сөннәткә утырта иде. Сүз тыңламаган шуграк малайларны еш кына «Баба килә!», «Бабага әйтермен!» дип куркытканнар. «Баба килә»нең халыкта «Папа килә!» варианты да бар.

Баба яисә папа ир балаларга ниндидер яманлык эшләүче куркыныч нәрсә булып аңлашылган. Төрки телләрнең күбесендә баба ир кешене аңлата. Ләкин азәрбайҗан теле диалектында баба шулай ук ана (мать) мәгънәсендә дә кулланыла ала. Русча баба – хатын-кыз, әби мәгънәсендә килә.

Баба нинди генә җенестән булмасын, курәсең, ул бик борынгы мифик ияне күз алдында тота. Телдә бабаның бабай вариантлы да мәгълүм. Хәзерге татар телендә ул өлкән яшьтәге кешене белдерә. Ләкин күк күкрәп яшен яшьнәгәндә, әле дә, балаларны куркытып, «Әнә, Алла бабай килә!» – диләр. Кара диңгез буе скифларының Зевска тиң аллалары – күк алласы нәкъ менә Папай дип аталган да.

Шул рәвешчә, ир балаларны сөннәткә утыртып йөрүче баба яки бабачы ул ак сакаллы гап-гади карт кеше булмыйча, чынлыкта, бик борынгы карашлар буенча, бабай-папай дигән мифик Атаның җирдәге бер вәкиле булып чыга. Икенче төрле итеп әйткәндә, кайчандыр элек ир балаларны бабай-папайдан «ашатып» кире чыгару өчен каядыр урманга яисә таулар арасына алып бара торган булсалар, соңга таба, вакытлар узу һәм заманалар үзгәрү белән, бабай-папай ак сакаллы баба, бабачы, сөннәтче кыяфәтендә авылдан-авылга, өйдән-өйгә йөреп, бик борынгы йоланың кайбер калдыкларын башкара торган булып киткән.

Халыктагы ышану буенча, бабачы (сөннәтче) «үзе йотып кире чыгара» торган малайларның йөздән берен чынлап та гарипләндерә торган булган. 99 ир баланың бары кечкенә тиресен кисеп алса, йөзенче малайның ул «җан җире»ндәге әгъзасын да кисеп алган, имеш. Димәк, бабачы аның чынлап та җанын алган.

Шушы уңайдан без урта гасырларга кадәр сакланган һәм шактый киң таралган икенче бер йоланы да искә төшерәбез. Монысы печтерү йоласы. Бу йола борынгы фарсыларда, гарәпләрдә, кытайларда һ.б. халыкларда киң таралган була. Борынгы Кытайда печтерү җинаять өчен җәзалауның бер төре саналган. Атаклы тарихчы Сыма Цян, мәсәлән, шул рәвешчә җәзаланган. Күбесенчә коллар һәм җинаятьчеләр печтерелгән, һәм бу гадәт, күрәсең, хуҗаның (аксөякнең) үз балаларын чынлап печтерү куркынычыннан саклап калу өчен башкарылгандыр. Үлеп терелү йоласы аша үтәргә тиешле аксөяк үсмерне бу очракта кол яисә җинаятьче алыштырган. Этнографиядә билгеле булганча, элекке заманнарда мондый «алыш-биреш» киң кулланылган. Монголларның «Яшерен тарих» дигән әсәрендә Үгедәй ханның чирләве турында сөйләнелә. Үгедәй хан терелсен өчен, аның берәр якын туганы үләргә тиеш ди камнар. Чыңгыз ханның кече улы Толуй камнар әзерләгән суны эчә һәм үлә. Үгедәй хан исән кала. «Алтын тобчи»да әйтелгәнчә исә, Толуй Чыңгыз хан чирләгәч үлә, ә Чыңгыз хан исән кала.

Кешеләрне генә түгел, хайваннарны печтерү гадәте дә нәкъ менә шундый нигездә барлыкка килгәндер дип уйларга була. Кояшка һәм башка аллаларга багышланган айгыр, үгез, тәкә кебек хайваннарны кайбер очракта чалганнар, ә кайбер очракта, күрәсең, бары печтерү белән генә канәгатьләнгәннәр дип әйтә алабыз. Татардагы алаша – печтерелгән айгыр шул турыда сөйли дә инде.

Сөннәткә (бабага) бирү дә, печтерү дә, шулай итеп, үлеп терелү йоласының бер калдыгы, бер чагылышы булып тора. Ләкин үлеп терелү йоласы үзе кинрәк планда корбан бирү йоласының дәвамы һәм бер тармагы ул.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

23 июнь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
27 июнь – Үзбәкстан яшьләр театрының «Сны Гамлета» спектакле (Н.Мазур).
28 июнь – Үзбәкстан яшьләр театрының «На бойком месте» спектакле (А.Островский).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28, 29 июнь – «Кармен» (Ж.Бизе).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

23 июнь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
27 июнь – Премьера. «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин).
29 июнь – 10.00 – «Тинчуринда кунакта» квесты. 18.30 – «Яратам! Бетте-китте!» (Л.Әминова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

23 июнь – «35 тән – 5» дип исемләнгән иҗат фасылын ябу тантанасы.
30 июнь – «Ал җилкәннәр» спектакленең ачык репетициясе (А.Грин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

23 июнь – 11.00 – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Зур залда 18.30 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь). Кече залда 19.00 – «Макбет» (У.Шекспир).
24 июнь – зур залда – «Сны Диснея» (И.Зәйниев). Кече залда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева).
25 июнь – фойеда – «Хәерле көн!» (Н.Егорова). Зур залда – «Золушка» (Е.Шварц). Кече залда – «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай).
27 июнь – 11.00, 13.00 – «Золушка» (Е.Шварц). 15.00 – театр бинасы буйлап сәяхәт.
28 июнь – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әкиятенә нигезләнгән).
29 июнь – «Аладдин» (гарәп әкиятенә нигезләнгән).
30 июнь – 15.30 – театр бинасы буйлап сәяхәт. 19.00 – «Авиатор» (Е.Водолазкин).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

23 июнь – танылган җырчы Ф.Шаляпинның 150 еллыгы уңаеннан «Душа и Родина» дип исемләнгән хор музыкасы концерты.

Сүз дә юк, осталыкны һәркем дә хуплый. Хезмәттәге осталыкны, әлбәттә. Әмма, ни гаҗәп, моның белән килешмәүче дә очрый тормышта. Казанга күченгән якташларымның фикере бервакыт таң калдырды.

Гади эшчеләр хөрмәткә лаек

Казансу аша төзелгән «Миллениум» күперен ачу тантанасын карагач, шул якташларым янына сугыласы иткән идем. Ишектән керүгә:

– Безнең күпер салучыларның осталыгы шәп соң. Казансу ярына узган ел гына аяк басканнар иде, быел тоташтырып та куйдылар! – дип сүзгә керешкән идем, хуҗабикә шундук кисәтү ясады:

– Без улыбыз янында эшче һөнәрен олыламыйбыз, аны түбәнчелек белән телгә дә алмыйбыз. Зинһар, төзелешме, заводмы, машиналар хуҗалыгымы – анда хезмәт итүчеләрнең берсе турында да сүз чыгарма!..

Мин аңлыйм: һәр гаиләнең үз кагыйдәләре булырга мөмкин. Якташларымның принцип дәрәҗәсенә җиткергән бу алымы үзенә күрә бер тәрбия чарасы икән. Унынчы сыйныфта укыган малайларына нинди һөнәр сайларга кирәклеген шулай кайгырталар. Соңрак, уллары өйдән чыгып киткәч, җентекләп сораштым. «Сабак»ны хуҗабикә аңлатты:

– Аның алдында гади хезмәт кимешен һич кенә дә данларга кирәкми, алай эшчене зурлау була. Баланың башында ялгыш фикер тумасын! Эшләп кеше баеганмы? Ни эше юньле түгел, ни әҗере юк... Без уңышлы кешеләр турында гына сүз алып барабыз. Әгәр өлкәннәр эшкуар-миллионерлар яисә дәүләт эшлеклеләре турында гәп корып, аларның уңышларына соклана икән, ул да шул тарафка омтылачак бит!..

Әйе, һәр гаилә үзенчә хыяллана! Юк, мин якташларыма, сез ялгыш юлда, дип әйтмим: сөекле улларына шундый киләчәк димлиләр икән, хәерле сәгатьтә! Егет алга таба да яхшы укысын һәм үзе яраткан һөнәрне таба алсын, дигән теләк белән аерылыштык без ул көнне.

Гәрчә мин алар белән һич килешә алмыйм. Гомумән, эшчене санга сукмауны тәрбия принцибы дәрәҗәсенә җиткерүне беренче тапкыр ишетүем иде ул чакта. Карьера ясау, уңышлы кеше булу! Гади хезмәт юлын сайлап, уңышка ирешергә мөмкинме? Туп-туры әйтә алам: хезмәтнең бик күп төрләрендә!..

Мисаллар кирәк дисәк... Завод эшчесен санга сукмаска кушкан таныштыма КамАЗ берләшмәсендәге двигательләр заводында җир җимертеп эшләгән токарь Васил Әхәтовны тәкъдим итәм. Токарь – ул көне буе станокта эшләүче, деталь ярычы. Ул үз хезмәте турында миңа болай сөйли:

– Үзем эштән талып уфтануны белмим. Цехка ашкынып киләбез. Безгә эш башыннан түлиләр, ягъни сдельщик без. Һәр детальне җәһәтрәк кырырга тырышасың, ә моның өчен осталык кирәк. Ничек остардыкмы? Бер-беребезгә карап чарландык. Кешедән калышасы килми, без, татар егетләре, үҗәт бит. Башкарылган эшкә карап түләнә торган хезмәт – ул үз-үзең белән ярышу кебек. Кызып эшләгәч, смена бетүен сизми дә каласың...

Васил яраткан эшендә югары квалификацияле токарь булып җитешә. Айлык планны өчәр, дүртәр тапкыр да арттырып үтәгән чаклары була. Әҗере дә шәп чыга. Хезмәт хакы кайсы айларда завод түрәләренекеннән дә югарырак була. Әлбәттә, нормировщиклар үлчәп-тикшереп теңкәсенә тия. Берсендә «ОТиЗ» җитәкчесе үзе килеп, көне буе күзәтә.

– Син миннән дә күбрәк акча аласың, – ди теге, аның кызулыгына аптырап.

– Мин аны эшләп алам бит!-дип җавап бирә ул аңа...

Ә инде хезмәтенең әҗере турында дәвам итсәк, ул гаиләсе өчен барын да булдыра. Кеше алдында кызарырлык түгел, ди үзе. Лаеклы ялга чыгар алдыннан хәтта туган авылында яңа йорт җиткерә, ә Чаллыдагы зур фатирына кызын күчерә. Авылдашлары: «Безнең Васил «КамАЗ» да эшләде!» дип, аның белән ихлас горурлана. Лаек та! Белгәнебезчә, илебез икътисады узган гасыр ахырында нык кыйналды, әмма авыр чакларда да КамАЗ берләшмәсе тез чүкмәде. Турысын әйтик: үзебезнең Васил Әхәтов кебек уңган эшчеләребез тырышлыгы белән җиңелде ул кыенлыклар.

Ә инде икенче мисал итеп төзелеш эшчесен, бик оста күпер салучыны күрсәтергә телим. Мәкаләм герое – Чаллы күпер төзү отрядының геодезия белгече Госман Сәлахов. Аның хезмәт биографиясендә төзелгән күперләр берничә. Алай гына да түгел, биналар да җитәрлек, шулар арасында Казанның Болак буен бизәп торган нәфис архитектуралы «Пирамида» да бар! Әйе, Чаллы күпер салучыларының хезмәт җимеше ул. Ювелир эше дип тә әйтерлек ул «Пирамида»ны! Матур сүз генә түгел бу. Геометрия фигурасын төзүдәге төгәллек буенча кырыс таләпне күтәрә алмый башка төзелеш оешмалары. Менә шуңа Казансу аша «Миллениум» күперен салуда ялтырап алган Чаллы осталарын чакыралар да инде. Отряд җитәкчелеге әлеге проект белән танышырга Сәлаховны алып бара. Мондый күнекмәгән төзелешкә тотыныргамы-юкмы дигән четерекле сорауга җавапны аннан көтәләр. Тәҗрибәле белгеч уңай җавап бирә. Төгәллек миллиметр нечкәлегендә үлчәнсә дә, күпер салучылар өчен таныш таләп икән ул!.. Егетләр күркәм корылманы килешенгән вакытка очлап та куя!

Биредә геодезия белгеченең нинди җаваплы һөнәр иясе икәнлеген чамалау кыен түгел. Гәрчә Сәлахов үзен гади эшче дип атый. Төзелеш-монтажчыга укып чыккач, ул КамГЭС плотинасын төзүдә тугыз ел эшли, аннары – Менделеевскидагы химия заводын коруда, аннары – Апатиты каласы янында шахта өчен ике тауны тоташтырган корыч күпер салуда... Шахталар ягыннан аларның оешмасы Ульяновск янындагы Идел күперен төзергә кайта. Идел ярларын тоташтыргач, атаклы Чулман күпере, аны узгач, Казансу аша «Миллениум» күпере һәм менә «Пирамида»!...

Соңгы күперләрне төзегәндә, Госманга инженер-геодезист вазыйфасын ышанып тапшыралар. Чулманныкын күпер дип әйтүебез бик үк рас килми әле биредә. Аны Чулман кичүе дисәк, дөресрәк булыр. Өч күпердән торган, җәмгысы 13967 метрга җиткән озын кичүне Чаллы күпер салучыларының иң әһәмиятле эше дип әйтерлек!

Күпер төзүче Госман Сәлахов һәм токарь Васил Әхәтов исемнәрен ачыктан-ачык күрсәттем. Үзләрен гади эшче дип әйтсәләр дә, алар уңышлы кешеләр. Үрнәк итеп куярлык тормыш корган алар.

Ильяс САЛИХҖАН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

24 июнь (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 6нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 10.10 сәгатьтә калка, 0.27 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Бака яфрагы шифасы

Цистит интектергәндә, 2 аш кашыгы бака яфрагы орлыгын 1 стакан кайнар суда 10 минут тønәтәләр һәм ач карынга 1 әр аш кашыгы кабалар.

25 июнь (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,11.26 сәгатьтә калка, 0.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Андыз сихәте

Артрит җәфалаганда, авыртуны болай басалар. 100 г андыз тамырын 1 литр суда 15 минут пешерәләр, 1 сәгать төнәтәләр, сөзеп, җылы суга кушалар һәм авырткан аяк-кулларны шуңа тыгып утыралар.

26 июнь (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,12.44 сәгатьтә калка, 0.37 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Сөтле икмәк

Икмәк йомшагын җылы сөттә җебетәләр дә, биткә сылап, 15 минут тоталар. Аннары җылы су белән юып, крем сөртәләр. Мондый битлек тиресе дымландыра һәм тукландыра, шешенүне киметә.

27 июнь (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 14.03 сәгатьтә калка, 0.43 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.32 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Склероздан дәва

1 әр кг кара миләш һәм шикәрне кушып болгатып, көнөнә 3 тапкыр 1 әр чәй кашыгы кабу склероздан һәм зоб авыруыннан саклый.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

28 июнь (чәршәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 15.26 сәгатьтә калка, 0.52 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Ревматизмнан куркыргамы?

Ревматизм беренче чиратта буыннарга, йөрәккә һәм нерв системасына һөҗүм итә. Табибләр, әлеге чир "буыннарны ялый, ә йөрәкне тешли", ди. Ревматизмнан даруларсыз гына дәваланып булмый. Ярдәмче чаралар сыйфатында халык медицинасы түбәндәгеләрне киңәш итә: 1) 15 г әрекмән тамырын 200 мл суда кайнаталар да, 2-3 атна буе көненә 4 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы кабалар; 2) көн саен 1 грейпфрут ашыйлар – андагы биоактив матдәләр буыннар өчен бик файдалы; 3)1 чәй кашыгы кизил тамырын 1 стакан суда 15 минут пешерәләр дә, 2-3 атна дәвамында көненә 3 тапкыр 2 шәр аш кашыгы эчәләр; 4) иртән ач карынга 1 стакан җылы суга 1 яки ярты лимон согы кушып эчәләр.

29 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 16.55 сәгатьтә калка, 1.01 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Сарымсаклы бал

Кан тамырлары варикоз киңәйгәндә болай дәвалану булыша. 250 г чистартылган, иттарткычтан чыгарылган (яки блендерда издерелгән) сарымсакны 350 г сыек балга кушып, әйбәтләп болгаталар, караңгы урында 1 атна тәнәтәләр, суыткычта саклыйлар. 1-2 ай буе, көненә 3 тапкыр, ашарга 40 минут кала 1 әр аш кашыгы кабалар. Мондый бал йөрәк өчен дә шифалы.

30 июнь (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 18.27 сәгатьтә калка, 1.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.30 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Эремчекле бөккән

500 г майсыз эремчекне иттарткычтан чыгарып, 1 йомырка, 100 г он, тәменчә тоз, ванилин кушалар да, камыр басалар. 12 тигез өлешкә бүлеп, һәркайсын җәяләр, уртасына җиләк-җимешле эчлек салып, бөккән бөгәләр. Үсемлек маенда йөздереп кыздыралар. Табынга өстенә шикәр оны сибеп бирәләр.

Туфрактан яратылган АДӘМ

Бәндәнең фани гәүдәсе туфрактан яратылганга күрә, туфрак белән ризыклана һәм ахыр чиктә туфракта юкка чыгар. Ягъни үзенең асылына кайта. Туфрактагы бөтен элементлар азмы-күпме дәрәҗәдә кеше тәне составына керә. Кеше тәне шул ук вакытта туфракның башка төрле формасы, күренеше ул. Адәм галәйһис-сәламнең туфрактан яратылуы аяти-кәримәдә: «…Аллаһ аны туфрактан яратты. Соңыннан аңа «Бул!» диде, (һәм ул) бар булды», – дип телгә алына («Әли Гыйммран», 59).

Туфрак кызыл, кара, ак һәм башка төсләргә ия булган кебек, аннан яратылган адәм балалары да төрле төстә. Шулай ук туфракның каты һәм йомшак яклары булган кебек, кешеләр дә сәләт һәм холык мәсьәләсендә бик төрле. Әлеге хакыйкатьне аяти-кәримә болай хәбәр итә: «Аллаһның күктән суны иңдергәнен күрмәдеңме? Аның белән Без төрле төсләрдәге җимешләр чыгардык. Тауларда да төсләре төрле-төрле – аклары, кызыллары һәм башка төсләрдә – булган юллар (ясадык). Кешеләрдән, җанлылардан һәм терлекләрдән дә төсләре төрле-төрле булганнар бар. Коллары арасыннан галимнәр генә Аллаһтан (тиешенчә) курка. Һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Гафу итүче» («Әл-Фәтыр», 27-28).

Бу мәсьәләдә Рәсүл Әкрәм саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһ Тәгалә Адәмне җирнең һәр тарафыннан алган бер тотам туфрактан яраткан. Шул сәбәпле Адәм балаларының, шул туфрак белән бәйле рәвештә, бер өлеше кызыл, бер өлеше ак һәм кара, бер өлеше исә катнаш төстә; бер өлеше йомшак, бер өлеше кырыс, бер өлеше яхшы холыклы, бер өлеше начар холыклы (ягъни төрле холыклы, үзенчәлекле һәм төрле сәләтле) булып дөньяга килә» (Әбү Давыт, «Сөннәт», 16).

Риваятьтә әйтелгәнчә, «Аллаһ Адәм халикъ кылыначак туфракны кырык көн изә». Бу көннәрдән һәрберсе без аңлый-төшенә алмаган вакыт берәмлеге булып тора. Чыганаклардагы мәгълүматларга караганда, Адәм яратылган балчык кырык ел үз хәлендә кала. Билгеле бер калыпта пешә. Өстенә утыз тугыз ел борчу-кайгы яңгыры, бер ел шатлык-куаныч яңгыры ява. Шуңа күрә адәм баласының борчу-кайгылары сөенечләрдән күбрәк.

Югарыда искә алынган бу яңгыр нин-дидер матди нәрсә, чын яңгыр түгел, абстракт төшенчә, яңгыр сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган. Кайгы-борчудан соң һәрвакыт сөенеч килә. Олуг нигъмәт-бүләкләр – зур сабырлык һәм кайгы-хәсрәтләрдән соң. Аяти-кәримәдә Аллаһ Тәгалә әйтә: «Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар. Чынлыкта да, авырлыктан соң җиңеллек бар» («Әл-Инширах», 5-6).

Коръәни Кәримдә Хәзрәти Адәмнең туфрактан яратылу этаплары түбәндәгечә аңлатыла.

1. Туфрак этабы

«…(Аллаһ) Адәмне туфрактан яратты, соңыннан аңа «Бул!» – дип әйтте, һәм ул бар булды» («Әли Гыйммран», 59).

Кеше туфрактан яратылганга күрә, туфракның төрле сыйфатларына ия. Туфрак үзле, комлы, каты, йомшак булган кебек, кешеләрнең холык-табигатенә төрлелек хас. Балчык бик яхшы изелә, аның белән бик җиңел теләсә нәрсә ясап була.

Балчык моңа бернинди дә каршылык күрсәтми. Кешедәге сабырлык, түземлек һәм кече күңеллелек әнә шуннан килә. Шул ук вакытта туфракның хәрәкәтсезлеге, тик торуы кешедә ялкаулык, иренчәклек кебек сыйфатларда чагылыш тапкан.

2. Юеш балчык этабы

«Ул һәр бар иткән нәрсәсен күркәм итте, кешене яратуны юеш балчыктан башлады» («Әс-Сәҗдә», 7).

Юеш балчык этабында су катнаша. Су, беренче чиратта, чистарткыч ролен үти һәм пакьлек элементы булып тора. Бу яктан караганда су кешедәге гыйффәтлекне, намусны һәм матди-рухи пакьлек хисләрен билгеләрә.

3. Ябышкак юеш балчык этабы

«…Һичшиксез, Без аларны (Адәмне һәм аның нәселен) үзле юеш балчыктан яраттык» («Әс-Саффат», 11).

Ябышкаклык, берегү кешенең тугрылык, бәйлелек хисен күрсәтә. Кешенең үҗәтләнүе, үзе яклаган фикерләрендә аяк терәп карышы торуы – бу этапның бер нәтиҗәсе.

4. Һавада кипкән дымлы балчык этабы

«Һичшиксез, без кешене (һавада) кипкән дымлы балчыктан, бер рәвешкә кергән балчыктан яраттык» («Әл-Хиҗер», 26).

Әлеге аятьтә искә алынган «салсал – һавада кипкән дымлы балчык» этабында «һава» элементы өстәлә. Һава кеше ясала торган балчыкка хәрәкәтлелек үзлеге алып килә. Адәм баласы холкындагы тотрыксызлык, үз фикереннән кайту, сүздә тормау һәм җимергә хирыслык сыйфатлары шушы этап нәтиҗәсендә пәйда була.

5. Бер рәвешкә кергән балчык этабы

«Менә Раббың фәрештәләргә әйтте: «Һичшиксез, мин (һавада) корыган үзле, бер рәвешкә кергән балчыктан кеше яратачакмын» («Әл-Хиҗер», 28).

«Хамә-и мәснүн – бер рәвешкә кергән балчык» этабы кешенең билгеле бер рәвешкә керү, тәрбияләнә, укытыла-өйрәтелә алу кебек үзенчәлекләренә ишарәли. Аның бу сыйфатының яхшы нияттә дә, начарга да файдаланылу мөмкинлеге бар. Иң мөһиме – бәндәгә дөрес юнәлеш бирә белү.

6. Утта яндырылган балчык этабы

«Аллаһ кешене утта яндырылган кебек чыңлап торган бер балчыктан яратты» («Әр-Рахман», 14).

Бу этапта процесска ут кушыла. Кешенең тәкәбберлек, горурлык, көнчелек, Аллаһ әмерләренә каршы килү, ялган сөйләү шикелле сыйфатлары уттан башлангыч ала.

«Әл-Мүэминүн» сүрәсенең 12-14 нче аятьләре Хәзрәти Адәмнән соң аның нәселеннән киләчәк һәр кешене ярату тәртибен түбәндәгечә бәян кыла: «Һичшиксез, Без кешене саф (сөзеп чыгарылган) балчыктан яраттык. Шуннан соң аны ышанычлы бер урын эчендә (аналыкта) тамчы иттек. Шуннан соң ул тамчыны оешкан канга (ябышкан һәм аталанган йомыркага) әверелдердек. Аннары ул оешкан канны мудга (бер чәйнәлгән ит) хәленә китердек, ул чәйнәлгән ит кисәген сөякләргә (скелетка) әверелдердек, шуннан соң ул сөякләргә ит кундырдык. Шуннан соң аны башка бер яратылыш белән (кеше буларак) бар иттек. Яратучының иң күркәме булган Аллаһ» («Әл-Мүэминүн», 12-14).

Медицина фәне бу мәгълүматларга бары безнең гасырда гына ирешә алды. Коръәни Кәримдә исә Җәнабел-Хак кешенең яралгы үсеше этаплары турында 1400 ел чамасы элек үк фәнни дөреслеккә туры килгән рәвештә хәбәр иткән.

Югарыдагы аяти-кәримәләрдә Җәнабел-Хак кешенең бик гыйбрәтле, игътибарга лаек яратылу этаплары турында сөйли. Бу этапларның әүвәлгерәге булган балчык, ягъни Хәзрәти Адәм яратылган туфрак этабының күренеш ягыннан бернинди кыйммәте дә, матурлыгы да юк. Шуннан соңгы этаплар исә – бер урынга атылган су тамчысы, авызда чәйнәлгәндәй рәвештәге оешкан ит кисәге – бер дә матур күренеш булмаган, хәтта җирәнү хисе тудырган нәрсә... Аннары илаһи кодрәт күренеше буларак, күркәмлек, матурлык манзарасына ия сәнгать әсәренә тиң кешенең барлыкка килүе... Соңыннан исә матдә белән рухның куәтлелеге һәм ныклыгы, ахыр чиктә бәндә әлеге үсеш сәфәренең янә беренче этабына таба кайтып, кабат туфракка әләгә һәм шунда череп югала!.. Аннары исә черегән тән эчендә, терекөмеш тамчысы шикелле, черемәгән һәм «асбуз-зәйнәб» дип аталган бердәнбер орлыктан, берәр үсемлекнең үсеп, өлгерү процессы тизәйтелгәндәй, кабат барлыкка килә һәм җанланып аякка баса!..

Җәнабел-Хак бик күп аяти-кәримәдә кешене бу муллык дөньясындагы мәҗарасы турында фикерләргә, уйларга чакыра:

«Без кемгәдер озын гомер бирсәк, аның яратылышта (көч-куәтен алып) киресен әйләндерәбез. Әллә алар (бу күренешне) аңламыйлармы? (Әлеге гыйбрәтле сәфәрне төшенә алмыйлармы)» («Йәсин», 68).

«Аллаһ сезне бер зәгыйфьлектән яратты, шуннан соң зәгыйфьлек артыннан куәт бирде, шуннан соң куәт артыннан көчсезлек һәм картлык бирде. Ул теләгәнен кыла. Ул – Белүче, Кодрәт иясе» («Әр-Рум», 54).

«Без сезне аңардан (туфрактан) яраттык, янә сезне аңа кайтарачакбыз, тагын бер мәртәбә сезне аңардан чыгарачакбыз!» («Та-һә», 55).

Бу хакыйкать шуны күрсәтә: кешенең тәне дөньяда кичерган этаплары һәм үзенең шәхси хәл-әхвәле белән фанилеккә мәҗбүр ителгән. Ә мөһиме һәм мәңгелеге – җан. Җәннәт-җәһәннәмгә бәхет яки газап юлы нәкъ менә җан белән үтеләчәк.

Ахир кытыклары

Башта җырлый, аннан елый

Арчада Тукай көннәре бара. Бер төркем язучылар, автобуска төялеп, шул якка кузгалдык. Шулчак телефоннан Ркаил (әле ул вакытта рәис түгел) шылтырата. Кая һәм кемнәр белән барганымны белеп алгач:

– Менә карап тор, Газинур Морат башта җырлар, аннан соң елар, – диде.

Ркаилнең сүзләренә артык игътибар бирмәдем, боларны бер шаярту итеп кенә кабул иттем. Әмма бераздан бу сүзләр тормышка аша башлады. Тантана узды. Күрәм, ресторанда Газинурның кәефе кисәк кенә югары күтәрелеп китте һәм ул, ике дә уйламыйча, «Мәдинә»сен башкарып чыкты. Җырлады инде бу, ярар, дип уйлыйм үземчә, тик кайчан елар микән? Кырлайдан соң, Өчилегә юл тоттык. Өчиледә өч укучы бала, халык алдына чыгып, өч шигырь укыды. Газинур түзмәде, шул өч баланы кочаклап: «Шушы өч татар баласының якты киләчәге өчен, гомерем беткәнче фидакяр хезмәт кылырга әзермен!» – диде дә, мышык-мышык килеп, еларга да тотынды. Мин шулчакта Газинурга түгел, ә Ркаилнең даһи күрәзәчелегенә шаклар катып сокланган идем.

Кызык гармунчы

Рәдиф Сәгъди гармунда яхшы уйный, җырлый да. Кайвакыт мин дә аңа кушылып җырлыйм. Бүлмәдә репетиция вакытында әйбәт кенә уйный, ләкин халык каршына чыкса, каушый, көйне табалмый. Бервакыт минем кичәдә катнашырсың, гармунда да уйнарсың, дип, аны туган авылыма очрашуга алып кайттым. Халык каршына чыктык. Уйный гына алмый. Шуннан бу, хәзер, көтеп торыгыз, дип фойега чыгып китте. Фойеда гармунын тарткалап-акырткалап, бер кадәр йөренгәч, көйне тапты бу, ниһаять! Кабат залга керде. Халык Рәдифне кул чабып каршы алды. Кирәк бит, кабат көен онытты. Тагын чыкты фойега, тагын керде. Халык, уйнаучының көе бозылмасын дип, селкенмичә, тын гына утырды. Афәрин! Уйнап чыкты, мин аңа кушылып җырладым.

Рәис шелтәсе

Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла әдәби консультант Марат Закирга:

– Син кайчан эшли башлыйсың? – дип шелтә белдергән.

– Эшлим бит инде! – дигән тегесе рәиснең күзенә туры карарга куркып.

– Кая? Нәрсә?

– Менә синең юбилей кичәңә чакыру билеты алдым. Бүген кичен Камалга барам... Эшкә ягъни...

Фикер җиткерүче

Шагыйрь Зиннур Мансуров Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдуллага зарлана икән:

– Нишләп соң сез ул Хәбир Ибраһимны кабул итү комиссиясенә әгъза итеп билгеләдегез соң, аңламыйм?!

– Ә нәрсә булган?

– Комиссия утырышларында ул барлык кандидатураларга да каршы килеп утыра, бер язучыны да берлеккә алдыртасы килми!

– Борчылма, – дип тынычландырган аны Ркаил, – ул минем фикерне җиткерә.

Тавыш ачылу сере

Камал театрыннан Зөлфәт Маликовны искә алу кичәсеннән хатын белән чыгып барабыз. Безнең алдан гына язучы Разил Вәлиев атлый. Хәл-әхвәлләр сораштык.

– Разил абый, мәйтәм, пенсиягә чыккач, минем тормышта ике зур вакыйга булды: беренчедән, яңадан өйләндем, икенчедән, әзрәк тавыш ачылды, җырлый башладым...

Абзый безгә карап-карап торды да:

– Менә шул яңадан өйләнгәнгә күрә, тавышың ачылган да инде синең, – диде, - сәхнәдә дә, көнкүрештә дә...

Экстрасенс

Туксанынчы еллар. Казан телевидениясендә эшлим. Иртәнге «Чулпан» тапшыруын ачтылар. Роза исемле ханым русча, ә мин татарча алып барам. Кичен әзерлисең, иртән күзеңне ертып чыгасың. Төнге икедә торып басасың, йоклап булмый. Иртәнге җидедә халык каршына чыгарга кирәк. Эфир турыдан-туры бара. Ул чакта йөрергә машинам да юк, таң тишегеннән иң беренче троллейбуска утырып, телевидениегә җилдерәм. Юлда барганда эчемнән: «Нишләп Ходай мине шул тиклем каргады икән, ничек кенә бу «Чулпан»нан котылырга микән?» – дип уйланып, сызланып барам.

